КАЗАХСТАН САБАГЫ

Анда булган кайнар вакыйгалар уйландыра

> 4

КОЛ ШӘРИФ

Без белгән һәм белмәгән тарихи шәхес

> 16

РӘФИНӘ ГАНИУЛЛИНА:

«Дөнья мине көрәшергә өйрәтте»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 4 (28777) | Җомга | 14 гыйнвар | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

pixabay.com

БӘХЕТЕМНЕ КИЧЕР

КИБЕРБУЛЛИНГКА НИЧЕК КАРШЫ ТОРЫРГА?

Рәхәт заманда яшибез инде: диванда кырын ятып кына да кемнеңдер эшенә, тормышына, кыяфәтенә бәя биреп утырырга мөмкинлегебез бар. Кемдер чын күңелдән соклана, кайсылары бу мөмкинлектән явызларча файдалана. Телефон экранын сыпыру, компьютер төймәсенә басу да җитә. Бер мәлне фикер белдерү дорфа мыскыллауга күчеп, арадагы чик югалмасын иде дә бит...

> 6

Ишетми калмагыз

Пенсия күбрәккә арта

Россия Президенты Владимир Путин пенсияләрне инфляциядән зуррак күләмдә – 8,6 процентка арттыруны тәкъдим итте. «Бу җәһәттән моңа кадәр кабул ителгән карар кешеләргә бәя үсү чыгымнарын каплау мөмкинлеге бирми. Шуңа пенсияләрне инфляциядән бераз югарырак дәрәҗәдә – 8,6 процентка индексацияләргә тәкъдим итәм», – диде ул. Дәүләт башлыгы сүзләренә караганда, хәзерге вакытта бәя үсү темпы 8,4 процент тәшкил итә. Президент Хөкүмәткә кирәкле барлык чараларны тизрәк башкарырга кушты.

Федерация Советы Рәисе Валентина Матвиенко белдергәнчә, закон әле кабул ителмәсә дә, пенсия инде 1 гыйнвардан 8,6 процентка арта. Россия Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгында әйтүләренчә, хәзер эшләмәүче пенсионерларның пенсиясе 18,984 сумга җитәчәк. Сүз уңаеннан, ел башыннан эшләмәүче кайбер пенсионерларга өстәмә түләү шартлары үзгәрә. 1992 елга кадәр колхоз-совхозларда, машина-трактор станцияләре, крестьян хуҗалыкларында эшләүчеләрнең һәммәсенә өстәмә акча түләнәчәк. Моңа кадәр аны хәзерге вакытта авылда яшәүчеләр генә ала иде.

Быел яхшырак булсын

Татарстанда яшәүчеләрнең 41 проценты 2021 елда тормыш-көнкүрешнең алдагысына караганда авыррак булганлыгын белдергән. hh.ru порталы үткәргән сораштыру нәтиҗәләре шундый. Сораштыруда катнашучыларның 33 проценты узган елның 2020 елдагыдан яхшырак булганлыгын, 21 проценты зур аерма сизмәгәнлеген әйткән, 5 проценты бу җәһәттән берни әйтә алмаган. Респондентлар арасында 18–24 яшьлекләр (36%) күбрәк уңай җавап биргән. 45–54 яшьлекләрдән – 48%, 55тән өлкәнрәкләрдән 46% 2021 елны тискәре бәяләгән.

Үзмәшгульләр 169 меңгә җиткән

Узган ел азагында республикада эшмәкәрләр саны (үзмәшгульләрне кертеп) 780 меңнән артып киткән. Шул ук вакытта үзмәшгульләр исәбе 169 меңгә җиткән. Алар өч ел эчендә – үзләренә махсус салым режимы кертелгәннән бирле – барлыгы 40,6 миллиард сум акча эшләгән.

Узган елда Татарстан Икътисад министрлыгы, үзмәшгульләргә ярдәм итү һәм аларны тагын да ишәйтү максатыннан, «Самозанятые» микрозаемын булдырган. 2021 елда 85 кеше шушы ярдәмнән файдаланган (барлыгы 13 миллион сум бирелгән). Моннан тыш министрлык үзмәшгульләргә Татарстан бюджетыннан субсидия бирү программасын эшләгән. Шул рәвешле 305 кеше эшмәкәрлек эшчәнлеге алып бару өчен кире кайтарылмый торган субсидия (барлыгы 50 миллион сум) алган.

Районнарда ни хәлләр?

Арча

Район бала тудыру йортында беренче булып дөньяга килгән кызчыкларны һәм аларның әниләрен каршы алырга туганнары белән бергә район башлыгы Илшат Нуриев та килде. Ул бәхетле әти-әниләргә бүләкләр һәм кызларының туу турында таныклыкларын тапшырды. «Икесе дә – кыз бала. Кыз бала туса, илгә табыш та була. Бәхетле сабыйлар булсыннар. Бүген без сезнең белән бергә шатланабыз, сөенәбез. Шушы чәчәкләр кебек матур итеп яшәргә язсын сезгә», – диде район башлыгы. Район үзәк хастаханәсенең баш табибы Рифат Идрисов исә Зифа белән Аянага үзләре кебек зурлыкта курчаклар тапшырды. Яшь әниләр Зилә Галиева белән Наталия Хөсәенова бала тудыру йорты коллективына рәхмәт сүзләре җиткерделәр.
(«Арча хәбәрләре»)

Менделеевск

Каладагы «Хөсәен» мәчетен 2022 елның августына ачарга ниятлиләр. Бу хакта аппаратның беренче киңәшмәсендә район җитәкчесе Радмир Беляев хәбәр итте. 3 катлы гыйбадәтханәне 2018 елның җәендә төзи башладылар. Мәчеттә ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен намаз заллары гына түгел, ә укучылар өчен ислам нигезләре буенча уку сыйныфлары да булачак.
(«Татар-информ»)

Әлмәт

Район башлыгы Тимур Нагуманов халыкка Яңа ел чыршыларын чүп-чар савытларына ташларга түгел, ә аларны алга таба эшкәртү өчен ишегалларына куярга киңәш итте. «Чыршыларны сезнең йорт янындагы контейнер мәйданчыгында калдырырга кирәк булачак. «Экосервис» чыршыларны җыячак, ә алга таба алар эшкәртелеп, терлекләргә азык буларак кулланылачак», – диде ул туры эфирда.
(«Әлмәт таңнары»)

Чистай

Милләтләр эше буенча федераль агентлык җитәкчесе Игорь Баринов, «Теләкләр чыршысы» акциясенә кушылып, Чистай кызы һәм аның гаиләсенең зур хыялын тормышка ашырды. Капитоновлар күптәннән кызлары Розаны ноутбуклы итү турында хыялланган. Күзләре начар күрсә дә, матурлыкны фотоаппарат объективы аша яхшы тоя икән кыз. Үзе төшергән сурәтләрне тагын да матурлар өчен ноутбук турында хыялланган ул. «Без, өлкәннәр, балаларның хыялларын тормышка ашырырга тиеш. Аннан соң, бүләкне кабул итүгә караганда кемне дә булса сөендерү күпкә рәхәтрәк бит. Бүген мин әлеге гаиләне сөендердем, аларның чын күңелдән булган хис-кичерешләрен күрдем. Татарстанга килүем бушка узмады – алар белән үзем дә сөендем», – диде Баринов. «Фото сәнгате белән дүрт еллап кызыксынам. Хәзер бөтен архивны ноутбукка күчерә алачакмын. Игорь Вячеславовичка бу бүләге өчен зур рәхмәт», – ди Роза үзе.
(«Чистай-информ»)

БАРЫСЫ ДА УРТАК

Бәйрәм генә түгел. Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын билгеләп итү уңаеннан узасы чаралар тарихны барларга, онытканны искә төшерергә һәм киләчәк турында уйларга этәргеч булырга тиеш. Иң мөһиме: алар мөселман өммәте генә түгел, янәшәдә яшәүче башка дин әһелләренә дә кагыла. Әлеге вакыйгага әзерлек һәм аны оештыру буенча республика комитетының киңәйтелгән утырышында шул хакта фикер алыштылар.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов тарихи вакыйга уңаеннан күздә тотылган чараларның Россия мөселманнарын берләштерүгә, мөселман традицияләрен торгызуга юнәлтелгәнен билгеләп узды. «Без Россиядә традицион конфессияләр арасында диалогка, төрле милләт һәм дин вәкилләренең дустанә яшәвенә уңай шартлар тудыруга зур игътибар бирәбез», – диде республика җитәкчесе. Безнең илдә төрле милләт вәкилләренең тату яшәвен бөтен дөнья күләмендә үрнәк күренеш дип атады ул. Президент фикеренчә, безнең бурыч – ата-бабаларыбызның гореф-гадәтләрен саклап калу. «Дөньяда ниләр булганын күреп торабыз. Кызганыч, төрле деструктив көчләр исламны кулланып, гомумән, бу дингә хас булмаган нәрсәләрне алга сөрергә омтыла», – диде Президент.

tatarstan.ru

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итү уңаеннан ил күләмендә узучы чаралар Россия Президенты Владимир Путин карары нигезендә оештырыла. Федераль оештыру комитетын Россия Хөкүмәте вице-премьеры Марат Хөснуллин җитәкли.

Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, истәлекле датаны бәйрәм итү республика һәм ил мөселман өммәте өчен күп еллар дәвамында традициягә әйләнде. Болгарда ислам динен кабул итү көненә багышланган «Изге Болгар җыены» беренче тапкыр 1989 елдан ук мөфти Тәлгать хәзрәт Таҗетдин тәкъдиме нигезендә үткәрелә. Шул вакыттан бирле ата-бабаларыбызның мирасын саклау буенча күп эш башкарылды. «Яңарыш» фонды эшчәнлеге нәтиҗәсендә зур күләмле тарихи-археологик тикшеренүләр, Болгар тарих-архитектура музей-тыюлыгы территориясендә мәдәни мирас объектларын реставрацияләү эшләре башкарылды. Моның өчен ул Россия Президенты Владимир Путинга да рәхмәтен җиткерде.

Президент фикеренчә, юбилей чаралары бай мәдәни мирасыбызны, традицион рухи кыйммәтләрне саклау һәм үстерүдәге уңышларыбызны, Россия мөселман өммәтенең ислам дөньясының алыштыргысыз өлеше икәнлеген бөтен дөньяга танытырга тиеш. Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан ил күләмендә барлыгы 71 чара уздырырга планлаштыралар. Шуларның иң зурлары – «Изге Болгар җыены», KazanSummit 2022 икътисади форумы, илкүләм татар дин әһелләре форумы, Җәмигъ мәчетенә нигез салу. Сүз уңаеннан, утырышта катнашучыларга Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуны бәйрәм итү логотибы проектын да тәкъдим иттеләр. Аны федераль оештыру комитетына да тәкъдим итәчәкләр. Билгеле булганча, әлеге комитетны Россия Хөкүмәте вице-премьеры Марат Хөснуллин җитәкли.

Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев ислам динен кабул итү белән бәйле тарихи юбилей тудырган мөмкинлекләрдән файдаланып калырга чакырды. «Бу – тарихи вакыйга. Владимир Путин карары нигезендә, аны зурлап бәйрәм итүнең нәтиҗәләре яхшы булачак. Ул милләтара татулык өчен бик кирәк. Бу вакыйгадан урыннарда файдаланырга кирәк», – дип мөрәҗәгать итте Шәймиев. Утырышта тәкъдимнәр дә булды. Россия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәтенең баш мөфтие Тәлгать Таҗетдин, мәсәлән, бәйрәм чаралары балалар, яшьләр тормышында да чагылырга тиеш, дип саный.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин быел рус телендә онлайн мәдрәсә ачылачагын да хәбәр итте. Мөфти, форсаттан файдаланып, мөселманнар мәнфәгатьләрен яклавы өчен Рөстәм Миңнехановка рәхмәт әйтте. «Россия мөселманнары мәнфәгатьләрен зур ихласлык, сәяси осталык белән якладыгыз. Дөрес һәм үткен сүзләр табып, согудиләрне үз ягыгызга күндерә алдыгыз. Барлык мөселманнар исеменнән зур рәхмәт сезгә», – диде Камил хәзрәт Сәмигуллин.

Олуг тарихи вакыйга белән бәйле чаралар бөтен Россия мөселманнары өчен дә зур вакыйга булачак. Шуңа күрә җыелышта башка төбәкләрдән килгән дин әһелләренең дә катнашуы гаҗәп түгел. Кырым мөфтие Эмирали хаҗи Аблаев Идел буе Болгар дәүләтендә исламның 1100 еллык тарихын мәдәни һәм социаль яктан зур әһәмияткә ия, татарларның һәм Россиядә яшәүче башка халыкларның милли үзбилгеләнүен формалаштыручы мөһим факторларның берсе дип атады. «Хәзерге җәмгыять үрнәк алырга тиешле тарих бу. Без кешелекнең, диненә һәм милләтенә карамастан, үзара мәхәббәт һәм хөрмәткә мохтаҗ булуына тагын бер кат инандык. Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллык тарихы ул вакытта көн кадагында булган әйберләрнең бүген дә актуаль булуын раслый. Без бер-беребезгә мохтаҗ һәм бу безнең борынгы бабаларыбызның кыйммәтләрен кире кайтарырга тиешлегебезне искәртә. Халкыбызның тормыш юлын билгеләгән бабаларыбызга хөрмәт бу», – диде Эмирали хаҗи Аблаев.

Кырым мөфтие мөселманнар, православие һәм башка традицион дин вәкилләренең татулыкта яшәвен искәртте. Киләчәк буынның төрле халык һәм дин вәкилләре арасындагы шушы дустанә мөнәсәбәтләрне алдагы меңьеллыкларда да саклап калуларын теләде ул һәм Минтимер Шәймиев белән Рөстәм Миңнеханов алып барган сәясәтне башкаларга үрнәк дип атады. «Аллаһы Тәгаләне онытучылар, кайбер күршеләребез кебек, җитди проблемалар белән очраша. Ходай безнең Россияне мондый авырлыклардан сакласын. Сезгә озын гомер, ныклы сәламәтлек телим. Башкалар да сездән үрнәк алсын», – диде Эмирали хаҗи Аблаев.

Россия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәтенең баш мөфтие Тәлгать Таҗетдин мәктәптә һәм югары уку йортларында әхлак дәресләре укытылырга тиешлеген әйтте.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

«ФАТИХА» БЕЛӘН ФАТИХА БИРЕЛДЕ

Олуг вакыйга уңаеннан Казанда Коръәнне кулдан яза башладылар. Башкаланың «Кол Шәриф» мәчетендә беренче сүрә – «Фатиха»ны 23 яшьлек каллиграф егет Артем Писаренко язды. Ул – Россия ислам институты каршындагы «Ән-Намир әл-Мухаттат» гарәп каллиграфиясе һәм ислам сәнгате үзәге директоры Рамил Насыйбуллинның шәкерте.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин сүзләренә караганда, Коръәннең кульязма варианты Согуд Гарәбстаны, Төркия, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Бәхрәйн, Күвәйт, Катар, Ливия, Марокко һәм Пакьстанда язылган инде. Хәзер бу исемлеккә Казан да өстәлде. «Элек ислам каллиграфиясе дигән мөһим фән булган. Без кириллицага күчкәч, бу фән онытылды, югалды. Әлеге фәннең нигезен Коръән язуы тәшкил итә. Шушы фәнне яңартып, бу эшне башлыйбыз», – диде мөфти кульязма Коръәннең әһәмияте турында сөйләгәндә.

Коръәннең бер битен күчереп язу өчен якынча ике көн вакыт кирәк икән. Аннары аны тикшереп, кирәк булса, төзәтмәләр дә кертәсе булачак. Шул рәвешле Коръәнне тулысынча күчереп язу өчен, ким дигәндә, ике-өч ел вакыт үтәр дип фаразлыйлар. Бу эштә Шиһабетдин Мәрҗани, Муса Бигиев китапларына нигезләнергә җыеналар.

КИТКӘН АКЧАНЫҢ КИРЕ КАЙТУЫ ӘЙБӘТ

Татарстанда төбәкнең тулай продукты күләме төбәк бюджеты керемнәренә караганда тизрәк үсә, чөнки федераль үзәк акчаны үзенә күбрәк каера. Шул ук вакытта ул республикага илкүләм проектлар аша һәм «инфраструктур меню» (икътисади, социаль үсешкә ярдәм) рәвешендә кире кайта. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Мәскәүдә Гайдар форумы кысасында узган фикер алышу барышында шулай дип белдерде.

oilcapital.ru

– Кайбер саннар китереп үтәм. 2010–2021 елларда төбәкнең тулай продукты 3,2 тапкыр артты. Ягъни 1 триллион сум булса, 3,2 триллионга җитте. Ә бюджет керемнәре нибары 2,4 тапкыр гына үсте. Федераль коллегаларыбызның адымнары акчаның бер тарафтан икенчесенә агуын күздә тота, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан Президенты искә төшереп узганча, узган елда республикада 1 триллион 150 миллиард сум чамасы салым түләве җыелган. «Без – «пассажир»лар түгел, без – федераль бюджетка әйбәт кенә акча җибәреп килә торган җитди төбәк. Нефть акчасы гына да түгел бу. Бездә яңа нефть эшкәртү комплексы бар, нефть химиясе комплекслары, КамАЗ заводлары яңартыла», – дип санап үтте республика башлыгы.

Президент әйтүенчә, төбәкләр бюджеты белән федераль бюджет арасындагы үзара мөнәсәбәтләр мәсьәләсендә, якларның мәнфәгатьләре төрлечә булу сәбәпле, уртак аңлашуга беркайчан да килеп булмый.

«Муниципалитетта эшләгәндә, миңа үзәктәге җитәкчеләр кайбер әйберләрне аңламый кебек тоела иде. Минтимер Шәймиев мине финанс министры итеп билгеләгәч, министрлыкта бик әзерлекле, профессиональ кешеләр эшләвенә төшендем», – дип хатирәләре белән уртаклашып алды Рөстәм Миңнеханов. Ул бюджет процессларын аңлауның башлыча җитәкченең нинди вазыйфада эшләвенә бәйле булуын искәртеп үтте. «Федераль дәрәҗәдә беркайчан да эшләгәнем юк, шуңа федераль коллегаларга дәгъваларым бар. Әмма мин федерация субъекты җитәкчесе буларак фикер йөртәм», – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов искә төшереп узганча, пандемия башлануга, Россия Президенты һәм Хөкүмәте тиз генә төбәкләр бюджетларына ярдәм итәрдәй мөһим карарлар кабул итте. «Шуңа хәзер Россия Хөкүмәтен тәнкыйтьләп булмый. Икътисади, социаль үсешкә ярдәм төбәкләр өчен зуррак мөмкинлекләр бирә. Иң мөһиме – Россия Хөкүмәтенең, кире уйламыйча, бу карарларны ахырына кадәр җиткерүе», – диде ул.

Шул ук вакытта Татарстан Президенты искәрткәнчә, федераль хакимиятнең фискаль сәясәт өлкәсендәге карарлары алдан фаразланырлык булырга тиеш, чөнки бу предприятиеләр икътисадына һәм инвестицион проектларны тормышка ашыруга йогынты ясый. Чиктән тыш ябышкак нефть чыгаруга ташламаларны бетерүне мисал итеп китергән ул. Нәтиҗәдә «Татнефть» гадәти булмаган нефть запасларын булдыруга җәлеп иткән инвестицияләрен югалтты. Моңа кадәр «Татспиртпром» дәүләт компаниясе шундыйрак хәлдә калды: зур градуслы эчемлеккә акцизлар федераль бюджетка китеп барды. «Даимилек мөһим. Биш-җиде ел тимәячәкбез, – дип әйтүләре кирәк», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан Президенты шулай ук, төбәкләр, федераль Хөкүмәт белән бәхәсләшсә дә, берсен берсе ишетүләрен әйтте. «Соңгы елларда «инфраструктур меню» һәм илкүләм проектлар рәвешендә төбәкләргә бик зур ярдәм күрсәтелә: акчаны алып, алардан файдаланырга гына өлгер», – диде ул.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Россия Инновацион регионнары ассоциациясе (АИРР) Советы рәисе итеп сайланды. Карар АИРР әгъзаларының гомуми җыелышы барышында күпчелек тавыш белән кабул ителде. Әлеге чара Гайдар форумы кысасында узды.

ФӘРИТ МӨХӘММӘТШИН:

«СЕЗ – БЕЗНЕҢ ПРОКУРОРЛАР»

Россия матбугаты көне уңаеннан журналистларны тәбрикләү гадәти генә булмады быел. 2022 ел Россиядә халыкларның мәдәни мирасына багышланачак. Шул уңайдан бәйрәм дә Татарстан Халыклар дуслыгы йортында узды. Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан халыклары ассамблеясы советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин исә журналистларны прокурорлар белән чагыштырды.

Чарада матбугат өлкәсендә эшләүчеләргә бүләкләр дә тапшырылды. Хезмәттәшебез – бүлек мөхәррире Гөлгенә Шиһапова Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләнде.

– Сезнең бәйрәм прокуратурага 300 ел тулган көннәрдә уза. Ә безнең өчен сез гел прокурор булдыгыз. Хакимият сезне тыңлый, нәтиҗәләр чыгара, карарлар кыла. Моның өчен сезгә рәхмәт. Мин журналистларга хөрмәт белән карыйм, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Үзегезнең материалларыгыз аша телевизор караучыларның, газета укучыларның кискен сораулары, четерекле мәсьәләләрен хәл итәргә булышасыз.

Парламент башлыгы коронавирус темасын да читләтеп үтмәде. Аңлашыла, аны да бер-береңнән читләшү, аралашырга ярамау, авыручылар арту, битлекләр кию алҗыткан. Әмма ул алга таба шушы шартларда яшәргә өйрәнергә кирәклеген тагын бер кат искәртте.

– «Кызыл зона»да булган һәр журналистка рәхмәттән башка сүз юк. Сезгә карап, мөгаен, бик күпләр уйлангандыр. Хастаханәләрдә сулыш аппараты белән ятучыларны күреп, чиргә карата мөнәсәбәтен үзгәртүчеләр дә булгандыр. Чынлап та, авыр хәлдәге кешене күрү күпләрне уйландыра, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Дәүләт Советы Рәисе Бөтенроссия халык санын алуны акытырткан өчен дә журналистларга җылы сүзләрен җиткерде. Үтенече дә бар: фейк хәбәрләргә карата игътибарлы булырга кирәк. Матбугат аннан өстен булырга, халыкның ышанычын яуларга тиеш.

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев исә коллегаларына беренче чиратта сәламәтлек теләде.

– Узып киткән ел җиңел булмады. Тик ни генә булмасын, газета укучыларга, телевизор караучыларга халыкчан язмалар, төпле материаллар кирәк. Ә вирус куркыта. «Омикрон» штаммы ике атнадан килеп тә җитәчәк, авыручылар 4 тапкыр артачак, диләр. Шуңа да сак булырга, үзебезне сакларга кирәк. Барыгызга да сәламәтлек телим, – диде ул.

Җәмгыять өчен кирәк

Татарстан Прокуратурасында Россия Прокуратурасының 300 еллыгына багышланган тантана узды. Хокук сакчыларын Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин котлады.

«Прокуратура дәүләтебезнең һәм җәмгыятебезнең хокукый нигезләрен саклый. Сез барлык хокук саклау эшчәнлеген җайга саласыз, җинаятьчелекне киметү өчен барысын да эшлисез», – диде ул, республика җитәкчелеге һәм парламент исеменнән мөрәҗәгать итеп. Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, прокурорның хакимият органнары һәм җирле үзидарәләр эшчәнлегендә законлылыкны күзәтеп торуы аеруча мөһим. Чөнки бу җәмгыять һәм халыкның мәнфәгатьләрен яклау өчен кирәк.

Дәүләт Советы Рәисе сүзләренә караганда, прокурорларның игътибары илкүләм проектларны, республика һәм муниципаль программаларны тормышка ашырганда да мөһим. Чөнки алар республика үсеше өчен кирәк. Фәрит Мөхәммәтшин Татарстан Прокуратурасының закон чыгару эшендә катнашуын да телгә алды. Анысы законнарны камиллаштерү өчен әһәмиятле. Ул прокурорларга район һәм шәһәр советлары сессияләрендә актив катнашырга тәкъдим итте. «Җирле депутатлар белән эшләү халыкка якынрак булырга, кешеләрнең нинди кыенлыклар кичерүен аңларга, аларның проблемаларын хәл итәргә мөмкинлек бирә», – диде ул.

Әйтеп кенә бактым

Алай да, болай да бергә-бергә...

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Чагыштырмача күптән түгел генә татар зиратында православие динендәгеләрне җирләүгә бәйле шактый ук зур тавыш чыгып алган иде. Көнендә үк берәр сүз әйтергә телем кычытып торса да, тыелып килдем. Чөнки дингә кагылышлы гаять нечкә мәсьәлә турында язу – шактый четерекле эш. Татарстан – күпмилләтле республика һәм берәр ялгыш сүз әйтсәң, кемнедер рәнҗетүең бар. Ә язарга кирәк. Чөнки үзем сөйләшкән-киңәшкән дин әһелләре дә андый проблема барлыгын һәм аның бик җитди икәнен әйтәләр.

Мәсәлән, дин белгече, күптәнге танышым Рамил хәзрәт Юныс, әле Түбән Камада эшләгән чагында ук, мөселманнар һәм православие динендәгеләр өчен аерым зиратлар булдыра башлаганнарын әйтте. Мин, әлбәттә инде: «Ни өчен татар зиратына башка диндәгеләрне җирләргә ярамый?» – дип сорадым. Аның җавабы мондыйрак иде. Һәр мөселман татар зиратында шунда җирләнгән дин кардәшләр рухына дога укый. Бу – дини канун, кабул ителгән әхлак кагыйдәсе. Ә башка диндәгеләрнең үзенчәлекле, башка йола-гадәтләре бар. Мәсәлән, православие динендәгеләр мәрхүмнәрне искә алганда хәмер кулланалар. Бер керәшен кардәшем, әле кабер өстенә аракы сибү гадәте дә, җылау-сыктау да бар, дигән иде. Урысча без аны «отпевание» дибез инде. Ә мөселманга татар зиратында җырлау гына түгел, кычкырып сөйләшү дә килешми, ярамый да.

Фани дөньяда «Алай да бергә-бергә, болай да бергә-бергә, безнең бергә булуыбыз калсын бөтен гомергә...» дип җырлап яшибез үзе, әмма бакыйлыкта хәлләр бүтәнчәрәк шул, андагы тормыш гасырлар буе килгән йола-гадәтләрне үтәүне таләп итә. Ягъни «Тормыш уставы» икенче була инде.

Соңгы елларда татар авыллары чуарлана башлады, бушап калган нигезләргә төрле халык килеп төпләнә, җир алып, йорт сала. Алар арасында төрле кавем, төрле дин тотучылар бар. Димәк, җирле җитәкчеләргә аларга «мәңгелек йорт»тан урын бирү хәстәрен күрә башлау кирәк. Кайбер авылларда зират янында күпмедер җирне койма белән әйләндереп алганнарын ишеткәнем бар. Шулай итеп заман үзгәрешләре зиратларга да кагыла башлады.

Бер дин әһеленнән туганнар каберлеге турында да сорашкан идем. Бит һәлак булган солдатларны уртак кабергә күмгәндә, аның милләте, дине турында уйлап торырга вакыт юк.

Каберлеккә мәрмәр таш куеп, шәһит киткәннәрнең исем-фамилиясен генә язалар. Сугыш белән бәйле истәлекле көннәрдә мондый урыннарда православие дине әһелләре үз йолаларын уздыра, су сибеп изгеләндерәләр. Кайчак «Ә муллаларыбыз кайда?» дигән сорау да туа. Мондый йолалар яшьләрне «кайнар нокта»ларга җибәргәндә дә үтәлә. Поплар солдатларны, хәрби техниканы да су сибеп изгеләндерәләр. Бит армиягә төрле дин тотучылар алына. Сугыш – сугыш инде ул, ил өстенә килгән афәт. Ул заманда нинди дә йола үтәү башка да кереп карамый, вакыты да ул түгел.

Бу сүзләрне аптыраганнан язам. Күңелгә үзеннән-үзе Тукайның: «... рус белән гомер кичердек сайрашып», – дигән сүзләре дә искә төшә дә, шөкер бүген дә дус һәм тату яшибез, дип уйлап куям. Тик менә бакыйлыкка күчкәндә генә ике арадан кара мәче йөгереп үтмәсен иде. Ике дөнья – бер морҗа, ягъни алай да, болай да бергә булып булмый икән шул.

КАЗАХ ГАМБИТЫ

Гыйнварның беренче көннәрендә Казахстанда булган кайнар вакыйгалар уйландыра һәм фикерләү сорый бездән.

Бердән, вазгыятьнең яшен тизлегендә үзгәрүе сискәндерә һәм шомландыра. Безнең бүген чагыштырмача тыныч һәм тотрыклы дип санаган тормышыбыз кискен алышынырга мөмкин икән бит. 2 гыйнвар көнне сыекландырылган газга, ягъни мотор ягулыгына бәяләрнең ике тапкырдан да күбрәккә артуына каршылык белдереп урамнарга чыккан казахлар берничә көн эчендә мәйданнарның утлы таба кебек кызачагын, бер мәгънәсезгә кан коелачагын, югары хакимияттә зур үзгәрешләр буласын, илгә тынычлык урнаштыру максатыннан аркадаш илләрнең гаскәрләре кертеләсен күз алдына да китермәгәндер, мөгаен.

Вакыйгаларны кайнар эздән күзәтеп барган без дә аларның мондый борылыш аласын фаразлый да, чамалый да алмадык. Хәтта Кремльдә дә мондый гамбитны көтмәгәннәр иде. Карарлар аяк өстендә кабул ителде, аяк киемен чабып барган килеш алыштырырга туры килде. Тарихта беренче тапкыр ОДКБ (күмәк куркынычсызлык килешүе оешмасы) – элекке совет республикаларының берничәсе катнашында төзелгән хәрби союз көчләре хәрәкәткә килде. Мәсьәләнең шундый кызык ягы бар: Азәрбайҗан – Әрмән конфликтында Ереван бик үтенеп сораса да, ОДКБ җитәкчелеге авызына су капты, кан коюда катнашмады. Дөрес, ул чакта юридик яктан нигезләрлек сәбәп бар иде: Азәрбайҗан сугыш хәрәкәтләрен халыкара җәмгыятьчелек әрмәннәрнеке дип танымаган җирләрдә генә алып барды, ягъни Әрмәнстан территориясенә һөҗүм булмады. ОДКБ исә бары тик аркадаш илләргә читтән һөҗүм булганда хәрәкәткә килә ала. Уставның 4 статьясында шулай язылган чөнки.

Хәзер инде казах мәйданына килик. Анда бик тыныч протест башланып китте. Дөрес, бик масштаблы иде ул. Югары җитәкчелек урам тавышын шуңа күрә тиз ишетте: газга бәяләр киметелде, хәтта кайбер төбәкләрдә ул элеккедән дә арзанрак бәяләнә башларга тиеш иде. Вакыйгаларның менә бу өлеше бик табигый агышта. Инфляциядән халыкның риза булмавы бик аңлашыла, мотор ягулыгы бәясе сикерүен кешеләр бик авыр кабул итә, монысы да – мәгълүм нәрсә. Алай шаулап урамнарга чыгу ярамый ул үзе. Инфляцияне ул ысул белән басып булмый. Тик шулай да тыныч протестка түзәргә була әле, сабырлык чиген узмаганда, ул кайбер уңай нәтиҗәләргә китерә дә ала. Ләкин Казахстандагы шахмат тактасында бөтенләй көтелмәгән һәм аклана алмый торган адымнар башланды: бер дә уйламаган фигуралар мәйданга чыкты һәм бар нәрсәне ватарга-җимерергә тотынды. Күп кенә шәһәрләрдә полиция халык ягына чыкты, армия көчләрен кемнәрдер юлда бикләп, коралсызландырырга һәм хәрби техниканы үз кулларына төшерергә керешкә.

Газета хәбәрчесенең телефонында Казахстаннан алынган берничә хәбәр бар. Гыйсъянчылардан качып котыла алган хәрбиләрдән аларны коткаручы кешеләр сорый: «Ник җавап бирмисез, ник каршы тормыйсыз?» – диләр. Әле

генә үлем куркынычыннан котылган хәрбиләр: «Приказ юк, ата алмыйбыз», – дип җавап бирәләр. Иң мөһиме: вакыйгаларны канлы юнәлешкә борып җибәргән үтерүчеләрнең кем икәнен аңлап булмый. Рәсми казах пропагандасы чит илдән килгән террорчылар турында сүз алып бара башлый. Президент Токаев «Твиттер»да 20 мең террорчы турында сүзләр әлә, әмма ул сүзләрне бик тиз алып ташлый. Бердәнбер кулга алынган «чит ил террорчысы» Кыргызстаннан гастрольгә килгән яшь музыкант булып чыга. Рәсми кыргыз хакимиятләре аны яклап белдерү ясагач, егетне азат итеп, иленә кайтарып җибәрергә туры килә. Юк ителгән бер генә «террорчы»ның мәетен дә күрсәтә алмагач, радикаллар моргларден мәетләрне урлыйлар дигән хәбәр таратыла. Инде дистә меңнән артык кеше кулга алынса да, аларның берсен дә телевидение аша халыкка чит ил кешесе дип тәкъдим итеп булмый.

Казахстанның төп каналында КНБ – Милли куркынычсызлык комитеты (бездәге ФСБ) адресына гаепләү ташлана. КНБ тауларда боевиклар әзерләгән дигән сүз аек акылга сыймаса да, дөреслеккә якын хәбәр игълан ителә. Комитет башлыгы Кәрим Мәсимов «дәүләткә хыянәт итү» дигән гаепләү белән кулга алына. Менә хәзер инде без вакыйгаларның агышы ни өчен кискенләшүен бераз аңлый алабыз кебек. Мәсимов – ике тапкыр Премьер-министр булган кеше, аның җитәкчелекне үз кулына алуга шәхси амбицияләре булмый калмагандыр, мөгаен. Яшерен хезмәтләр өчен илдә түнтәрелеш оештыру зур проблема түгел. Тауларда боевиклар булганмы-юкмы – анысы башка мәсьәлә. Мәсимовның «досье»сын ачып карасак, аның АКШ Президенты Байден гаиләсе белән, элекке Англия Премьер-министры Тони Блэр белән дуслыгы һәм тыгыз элемтәләре барлыгы турында мәгълүматка тап булабыз.

Казах протестын ике өлешкә аерып куеп була: махсус оештырылмаган стихияле урам күтәрелеше һәм шуны файдаланып, югары элиталарның үзара сугышы. Токаев позициясенә басабыз да аны аңларга тырышабыз. Ил эчендә зур сугыш бара, кемнең кем яклы икәнлеген дә аңларлык түгел. Армия, полиция, яшерен хезмәтләрнең берсенә дә ышанып бетеп булмый. Ярдәмгә көчләрне читтән чакырырга туры килә. Уенга ОДКБны тартып кертү шул максаттан оештырыла. Чит ил агрессиясе турында рәсми игъланнардан башка гына хәрби блокны хәрәкәткә китереп булмый. Карар тиз кабул ителеп, ОДКБ көчләре керә башлагач, кайнар башлар тиз суына, эшнең зурга киткәнен инде фетнәне оештыручылар да аңлый башлый. Армия һәм аның югары җитәкчелегенең Токаевны яклавы да мәгълүм була. Берничә хата җибәргән югары офицерларның соңгы көннәрдә үз-үзләренә кул салуы казах мәйданының зур драма икәнен, тетрәндергеч фаҗига икәнен аңлата.

Казах мәйданының тагын бер катлаулы ягы бар: илнең төньягында руслар күпчелекне алып торган Караганда өлкәсе урнашкан. Төньяк территорияләрнең Россиянеке булырга тиешлеге турында ым-ишарәләр рус милли көчләре тарафыннан да, хәтта кайвакыт рәсми авызлардан да яңгырамады түгел. Әмма Мәскәү аек акыл белән эш итте: яңа «ДНР»га нигез салынмады. Инде хәзер ОДКБ көчләре ничек тиз кергән булса, шундый ук тизлек белән кире чыгарыла һәм бу – бик уңай күренеш. Аларның Казахстанда озак вакыть калулары, бер пуля да атылмаган очракта да, бик зур геосәясәи тетрәнүләргә китерә ала иде. Кытай ягы дипломатик тел белән үзенең бу вазгыятьтән канәгать үк түгеллеген аңларлык итте. АКШ лидерлыгындагы Көнбатышның мөнәсәбәтен инде әйтеп тә тормыйк.

Казахстанда көймә чайкалуы ул – Россия өчен зур яшен. Бик озын кору җир чиге. Аны ныгытып, бикләп бетереп булмый. Россия Урта Азия республикаларына бары тик Казахстан аша гына үтеп йөри ала. Ә алар белән икътисади бәйләнешләрне өзәргә ярамый. Көнбатышта НАТО блогы белән сөйләшүләрдә уңышка ирешеп булмады. Көньяктагы гаҗәп зур мәйданның үзәңә дошман көчләр йогынтысында калуына да, чайкалып торган вазгыятькә дә юл куярга ярамый. Әмма төбәктә артыгын да кыланып булмый, чөнки Кытай – Төркия – Көнбатыш – Россия мәнфәгатьләре үзара кисешеп беткән урын ул, андый кисешкән ноктада кыска ялганыш булып, ут чыгу бик тиз. Мәскәү шуңа күрә салкын акыл белән эш итә һәм сак кылана дип аңлыйк.

Бу юлларның авторы инде берничә ел дәвамында казах җәмгыятьчелегенең карашлары белән танышып яши. Алар турында шагыйрь теле белән: «Вулканнар бар диңгез төбендә...» – дип кенә әйтеп була. Шуңа күрә гыйнвар башындагы вакыйгалар – казах драмасының беренче акты дип белдерә алабыз. Аның прологы берничә ел элек канга батырылган халык күтәрелеше рәвешендә уйналган иде инде. Тагын бер нәрсәне искә төшерик: Горбачев идарәгә килгәч, СССРда иң беренче милли гыйсъянчылык күтәрелеше Казахстанда булды, бөек державаның нигезен какшата торган тектоник үзгәрешләр шуннан башланып китте. Драманың икенче акты кайчан уйналыр, әйтә алмыйбыз. Әмма зур кайтавазы бүген безгә дә килеп җитте. «Российская газета»ның чәршәмбе санында «Эре ретейлерлар төп продуктларга бәяне төшерү белән килештеләр» дигән язма бар. Аннан башка да сәяси элиталар эчендәге кайтавазлар күзәтелә, әмма алары тышка яңгырамый инде аның.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

ТЫНЫЧЛЫКТА КАЛДЫРМАС

КОРОНАВИРУСНЫҢ ЯҢА ДУЛКЫНЫН КАЙЧАН КӨТӘРГӘ?

Яллар узды, чир китмәде. Россия коронавирусның «омикрон» штаммы аркасында яңадан авыру өермәсендә калмагае. Чит илләрдәге хәлләр бездә кабатланмасынга әзерлек өчен тагын ике атна вакыт бар. Бу җәһәттән Россия, аерым алганда Татарстан нәрсә эшләргә җыена?

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Киеренкелек саклана»

Россия коронавирусның яңа дулкыны алдында тора. Ил башлыгы Владимир Путин, әзерлек өчен ике атна вакыт бар, дип белдерде. Хөкүмәт әгъзалары белән очрашуда вазгыятьнең иң начар борылышына әзер булырга кирәклеге турында кисәтте.

– Коронавирус безне дә, бөтен дөньяны да тынычлыкта калдырмый. Күренеп тора: киеренкелек саклана, вазгыять бик катлаулы. Бәйрәмнәр күп булды, кешеләр аралашты, болар барысы да эпидемиологик хәлгә тәэсир итми калмас, – диде дәүләт җитәкчесе.

Вице-премьер Татьяна Голикова Президент сүзләрен сан теленә күчерде. Ил күләмендә коронавируска каршы күмәк иммунитет дәрәҗәсе 63,2 процентка җиткән икән. Шул ук вакытта бу күрсәткеч Россиянең 12 төбәгендә шактый кимегән. Бу инде Яңа ел ялларына да, 6 ай элек вакцина ясаткан кешеләрнең кабат прививка кадатмавына да бәйле. «Аңлашыла: чирләүчеләрнең артуыннан котылып булмаячак», – дип кисәтте Татьяна Голикова.

Шомлы саннар янында өмет уятырдайлары да юк түгел. Вице-премьер чыгышыннан аңлашылганча, 2021 елның декабрь аенда үлүчеләр саны, ноябрь ае белән чагыштырганда, 16,4 процентка кимегән. 2020 ел декабре белән чагыштырсаң – 11,6 процентка. Гыйнвар башында үлүчеләр саны, былтыргы күрсәткечләр белән чагыштырганда, 24,5 процентка азрак икән.

Хөкүмәт әгъзалары, вазгыятькә бәйле рәвештә өстәмә чаралар күрергә кирәклеген аңлап, тәкъдимнәр әзерли. Владимир Путинга аларны атна ахырына кадәр күрсәтергә җыеналар.

Россия Президенты хастаханәләрне һәм сәнәгать тармагын «омикрон» таралуга мөмкин булганча әзерләнергә чакырды. Фармацевтика, кислород битлекләрен һәм шәхси саклану чараларын җитештерү юнәлешенә аеруча кагыла бу. Шул ук вакытта коронавируска каршы тест тапшыру һәм вакцина ясатуны да арттыру сорала.

«Авыручылар артачак»

«Омикрон» штаммы чир йоктыручылар санын 4 мәртәбә арттырачак. Оператив штабның «туры эфир»ы вакытында Татарстан вице-премьеры Ләйлә Фазлыева шул хакта белдерде. Әлегә республикада инфекциянең яңа төрен йоктырган кешеләр юк. Шулай да бу тынычланырга сәбәп түгел. Бары тик вакыты гына җитмәгән әле.

– Коронавирус инфекциясенең авырлыклары безгә кагылмасын дип, вакцина ясаттык. Хәзерге вакытта Татарстанда яшәүчеләрнең күпчелеге прививка кадатырга карар кылды. Әлбәттә, бик зур иммунитетка ирешә алмабыз. Моннан тыш, «омикрон»ның төбәкләргә үтеп керүенә бәйле рәвештә авыручыларның дүрт тапкыр артуы көтелә, – дип сөйләде Ләйлә Фазлыева.

Штаммы яңа булса да, саклану чаралары үзгәрешсез кала. Вакцина ясатуга аерым игътибар бирергә кирәк.

– «Тагын авыру көтелә икән, ни өчен вакцина ясаттык соң?» дигән сораулар еш килә штабка. Халык вакцина ясаткан һәм күмәк иммунитетка ирешкән икән, чир булса да, ул җиңелрәк узачак. Бу бөтен дөнья буенча шулай, – дип аңлатты Ләйлә Фазлыева.

Сүз уңаеннан, Татарстанда барлыгы 2 306 478 кешегә вакцина ясалган. Шуларның 1 866 321е вакцинаның икенче дозасын алган.

Сәламәтлек саклау министрлыгы да хәзер прививка кадату өчен уңай вакыт дип искәртә. Министрның беренче урынбасары Альмир Абашев сүзләренчә, чирләүчеләр саны кискен артканчы, халык чарасын күрсен – вакцина ясатсын иде. Бигрәк тә 60 яшьтән өлкәнрәкләргә кагыла бу. Альмир Абашев әйтүенчә, күмәк иммунитетка ирешү өчен чама белән тагын 5 процент җитми.

Тармак «омикрон»га да әзерләнә. Альмир Абашев әйтүенчә, галимнәр мәгълүматларына караганда, «омикрон» авыруның кискен формаларына китермәячәк, әмма төп авырлык сырхауханә хезмәткәрләренә төшмәгәе.

– Амбулатория-сырхаухәнә тармагы әзерлек алып бара. Чирләүчеләр саны артса, медицина юнәлешендә белем бирүче уку йортларыннан 700ләп ординаторны республика сырхауханәләренә җибәрәчәкләр. Алар чир белән көрәштә үз өлешен кертәчәк, – диде министр урынбасары.

Локдаун булырмы?

Тулысынча чикләнергә, ягъни локдаунны көтәргәме соң? Бу сорауга фаразлар гына бар. Әйтик, Дәүләт Думасының Сәламәтлек саклау комитеты башлыгы Дмитрий Хубезов әйтүенчә, «омикрон» аркасында локдаун игълан ителмәс. Хәер, билгеле бер чикләүләр кертү ихтималы бар.

Россиянең элеккеге баш санитар табибы Геннадий Онищенко исә инде хәзердән үк читтән торып эшләүгә күчәргә кирәк дигән фикердә.

– Эш бирүчеләр моны берни дә көтмичә эшләргә кирәклеген аңларга тиеш. Бу бит әле локдаун дигән сүз түгел, – ди ул. – Эш бирүчеләр аз гына чирләп торган хезмәткәрләренең хәленә керергә тиеш. Андыйларга өйдә калу кирәк.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ИМИНЛЕК БӘҺАСЕ

Барысы да – кешеләр хакына. Социаль иминиятләштерү фондының Татарстан бүлеге хезмәткәрләре 2021 елга әнә шундый шигарь астында нәтиҗә ясады. Ел ничек кенә авыр узса да, халыктан килгән гаризалар кире кагылмаган, җиде нульле саннар белән исәпләнүче чыгымнар да юкка китмәгән.

Гаризалар димәктән, 2021 елда Социаль иминиятләштерү фондының төбәк бүлеге барлыгы 600 меңләп гариза кабул иткән. Цифрлаштыру елына аяк басуыбызны исәпкә алып, фондның төбәк бүлеге җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Фердинат Закиров әлеге гаризаларның 500 меңгә якыны электрон форматта булуны ассызыклады.

– Тагын шуны әйтергә кирәк: Татарстан кәгазьдәге «больничный»дан тулысынча баш тартырга әзер. 2022 елның 1 гыйнварыннан вакытлыча хезмәткә яраксызлык («больничный»), йөклелек, бала тапкан өчен, сабый туганнан соң барлык пособиеләр электрон документлар булган очракта гына түләнәчәк. Ягъни документ форматын үзең сайлау мөмкинлеге булмаячак. Әйтик, булачак әниләргә бала табу сертификаты медицина оешмасына исәпкә басу белән электрон форматта биреләчәк, – диде ул.

Киңәшмәдә күтәрелгән тагын бер мөһим темаларның берсе – коронавируска каршы көрәш чаралары. Әлеге чараларга фондның төбәк бүлеге барлыгы 6,5 миллиард сумнан артык акча тоткан. «Барлык түләүләр дә вакытында һәм тулы күләмдә түләнде», – диде Фердинат Закиров. Моннан тыш, Россия Президенты Владимир Путин фәрманы нигезендә, республикада коронавирус инфекциясе йоктырган авырулар белән эш итеп, сәламәтлегенә зыян китергән медицина хезмәткәрләре һәм «ашыгыч ярдәм» машинасын йөртүчеләр бер тапкыр бирелә торган түләүләр алган. Аларның гомуми суммасы 218 миллион сумны тәшкил иткән.

Фонд эш урынында имгәнү очраклары һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри иминиятләштерүгә дә зур игътибар бирә. «2021 елда иминиятләштерүнең әлеге өлкәсенә сарыф ителгән чыгымнар 2 миллиард сумнан артып китте», – диде Закиров. Теманы дәвам итеп, Татарстанның вице-премьеры Ләйлә Фазлыева кабат куркынычсызлык турында искәртте.

– Имгәнгән кешене савыктыруга караганда, аны бу имгәнүдән саклап калу кулайрак һәм җиңелрәк. Без республика халкының куркынычсызлыгы өчен кулыбыздан килгәннең барын да эшләргә тиеш. Хәзерге вакытта төп игътибар коронавирус инфекциясе белән көрәшкә бирелсә дә, эш урынындагы иминлек – мөһим өлкәләрнең берсе, – диде ул үз чыгышында.

Сүз уңаеннан, фонд бюджетыннан ике меңнән артык оешмага барлыгы 500 миллион сум күләмендә ярдәм күрсәтелгән. Бу акча исә эшчеләрнең хезмәт шартларын яхшыртуга тотылырга тиеш.

Россиянең Социаль иминиятләштерү фонды хезмәтләре буенча сорауларыгыз туса, бердәм колл-үзәккә – **8-800-6-000-000** номерына шалтыратырга мөмкин. Шалтыратулар Россиянең барлык төбәкләреннән дә кабул ителә.

Фондның төбәк бүлегендә **8 (843) 216-00-19** номерлы «кайнар линия» дә эшли.

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

pixabay.com

БӘХЕТЕМНЕ КИЧЕР

Интернет, социаль челтәрләр барлыкка килү онлайн мәйданчыкта үзеңне танытмыйча гына башкаларга яла ягарга, бер сәбәпсезгә бәйләнергә мөмкинлек ачты. Хәзерге вакытта моннан аеруча күп кеше зыян күрә. Кеше сүзе кеше үтерә дигәннәренең дә никадәр рас булуын ачып салды ул. Сөякләргә су күтәрмичә түгел, ә психикасына, сәламәтлегенә, аңына тәэсир итеп, күпме кешенең якты дөнья белән хушлашуы да сер түгел. Бер сүз белән бу күренешне онлайн мыскыллау – кибербуллинг дип атыйлар.

Сәбәп нәрсәдә?

Бәя бирү, тәнкыйтьләү теләге һәм ачу күп. Кибербуллинг күренеше ешаюга шулар да сәбәп дип саный **«Матбугат.ру» порталы җитәкчесе Данил Сәфәров**.

– Бу гадәти тормышта да күзәтелә, ә онлайнда инде мондый кешеләр бигрәк рәхәткә чыга. Ник дигәндә, күзгә-күз карашу юк. Иркенлек! 2008 елда «Матбугат.ру» сайтын ачкач, админ буларак, күп кенә укучылар калдыра торган фикер-шәрехләмәләрне бетерергә туры килде. Ике танышым бер-берсе белән талашып китсә, икесе дә миңа үпкәләп кала иде, – ди ул. – Аннан шундый хәлне күзәтә идем: берәр театрда премьера булганда, үзебезнең кешеләр социаль челтәрләрдә актерның, режиссерның сәхифәсен күрсәтеп, рәхмәт укый, аннан, сайтка кереп, шул ук кешеләр исемен күрсәтми генә тәнкыйть чәчә. Икейөзлелектер инде бу. Шулай ук әчке комплекслардан да киләдер. Гомәр Хәйям әйткән бит: «О нас думают плохо лишь те, кто хуже нас. Те, кто лучше нас... им не до нас».

Кайбер тикшеренүләр раслаганча, кибербуллинг белән күбрәк балалар, яшүсмерләр очраша. Моны агрессияне чыгару ысулы дибез икән, бала аңына кайдан килеп кергән соң ул? **«Югары икътисад мәктәбе» иллүләм тикшеренү университеты хезмәткәре, психология фәннәре кандидаты Александра Бочавер** сүзләренчә, агрессия хисе барлык кешеләргә дә хас, әмма аның күләме социаль мохиткә бәйле.

– Әгәр дә бала аны чолгап алган кешеләр тыныч аралашкан, имин мохиттә үсә икән, ул да үзен шулай тотачак. Агрессив мохиттә башкача. Әйтик, мәктәптә укытучы балаларга кычкыра, өйдә дә көч куллану күренешләре бар, ди. Бу очракта баланың да усаллыкны белдерү ихтималы арта гына. Пандемия, билгесезлек, канәгатьсезлек кебек төшенчәләр дә мөһим. Кешеләр эшләрен, якыннарын югалта, киеренкелек арта. Бу чынбарлыкта да, социаль челтәрләрдә дә чагыла. Яшүсмерләр үзләре күргән тирәлеккә иярә, охшарга тырыша, – ди белгеч.

Азмы-күпме танылган кешеләр кибербуллингка охшаш күренеш белән ешрак очраша, әлбәттә. **Журналист Рәмис Латыйпов**, блогер вазыйфасын алган кеше үз өстенә халык белән эшләү йөкләмәсен дә алуын онытмасын, ди.

– Кайдадыр чират торганда, транспортта, кеше белән аралашкан теләсә кайда агрессив, көнче, ачулы, «вампир» холыклы начар кәефлеләргә тап булган кебек, социаль челтәрләрдә дә бар инде алар. Анда күбрәк, билгеле. Күзеңә карап, тәнкыйть, начар сүз әйтергә йөрәкләре җитмәгәннәр өчен социаль челтәр җәннәт кебек. Мин законны кырысландыру ниндидер файда бирә дип уйламыйм. Законның бар кешегә карата да тигез үтәлүе кирәк. Ә ул кешесенә карап үтәлә. Социаль челтәрләрнең үз фильтрларын кулланырга киңәш итә алам. Ошамаса, «хейтер»ларыңны блокка куярга, шәрехләмәләргә дә фильтр кулланырга була. Минә бу очракта безнең ил социаль челтәрләренә караганда чит илнекеләр яхшырак та эшли әле. Әле кайчак арттырып та җибәрәләр – юк кына гаеп өчен аккаунтны да ябып куялар. Андый очраклар да аз түгел. Чит илнекеләрне дә демократия учагы дип әйтә алмыйм. Законнарның кырыслыгыннан бигрәк, ачык һәм анык кануннар, гаделлек булсын иде. Алайса берәр кеше канлы җинаять күренеше элеп куеп, миллионлаган лайк җыя, ә син үзеңнең милләтеңне яклаган постың өчен «милләтара ызгыш уята» дип блокка китәсең. Яшерен аккаунтларга каршы көрәшә башласалар, «дошман»нардан үч алуның башка ысуллары пәйда булачак, – дигән фикердә ул.

Татарстанның атказанган артисты Илсөя Бәдретдинова белән дә бу хакта сөйләшкән бар иде. Җырчының социаль челтәрләрен күзәтеп баручылар беләдер: аның шәхси «хейтер»ы – Саимә исемле язылучысы бар. Артистның бер генә гамәлен дә бәяләмичә калмый ул.

– Һөнәрем буенча кирәкмәсә, мин, гомумән, «Инстаграм»да утырмас идем. Социаль челтәрдә адекват булмаганнар күп, барысына да игътибар итә торган түгел. Әз генә «дурак» булырга кирәк. Ләкин шул сүзләр арасында күтәреп булмый торганнары да бар, – ди мондый күренешләр турында Илсөя Бәдретдинова.

Телевидениедә эшләп алган Айгөл (исеме үзгәртелде. – **Ред.**) дә – интернет аша психологик басым ясауны кичергән кеше. «Бер кыз иде ул. «Инстаграм»да минем язмаларым астына тормышка өйрәтеп, көлемсерәп, фикерләрен калдыра башлады. Җавап язмый гына, бетереп бардым. Аннан туры үземә язарга тотынды. «Син – халык алдындагы шәхес, андый сүзләрне генә күтәрергә тиешсең», – ди. Ачыктан-ачык яшәргә өйрәтә инде. Әле ул минем сурәтләр, исем белән сәхифә булдырган. Күргәч, ризасызлык белдердем, аннан фан-сәхифә дип үзгәртте. «Блок» куюга кадәр барып җиткәч, башка язмады», – дип сөйләде ул.

Блогер Ринат Галиәхмәтов исә сүз белән тәэсир итүнең башка ягына игътибар итте.

– Бервакыт әни әти белән бергә төшкән фотосурәтен социаль челтәрдә урнаштырды. Моңа берәү: «Кыланчык», – дип язды. Моны бит яратып, «ии, кыланчык» дип тә укырга була. Шул ук вакытта дорфа иттереп тә. Әни аны «блок»лап куйды. Бу кеше миңа яза, әниегезне күрмим, яратып карый идем, ди. Әнидән сораштым, аннары бу кешегә яздым. «Мин аңа ул сүзне яратып яздым», – ди бу. «Смайл булса да куегыз», – дим. Чөнки елмаюсыз язылган һәр сүзне хәзер мыскыллауга тиңлиләр, – дип сөйләде ул. – Теләсә нәрсә язып утырулар закон тарафыннан контрольгә алынса, бик яхшы инде. Махсус язып утыручыларга азмы-күпме җәза күрелсә ярый. Тик ялган сәхифә ачу берни тормый. Шуңа күрә андый сүзләрне юньле кеше язмаганын шундук аңларга һәм игътибар итмәскә генә кирәк. Икейөзле кешеләр күп. Мин: «Безнең андый нәрсәгә иммунитет бар инде», – дим.

Хокук дөньясында «кибербуллинг» төшенчәсе рәсми төстә теркәлмәсә дә, Җинаять кодексында булган башка маддәләр буенча мыскыл итүчене җавапка тартырга мөмкин. Мисал өчен: кешегә үтерү янаса сәламәтлеккә зыян китерү белән янау – 119 маддә, яла ягу – 128.1 маддә, шәхесне хурлау – 130 маддә, хулиганлык – 213 маддә, җенси характердагы гамәлләргә мәҗбүр итү – 133 маддә.

Сүз уңаеннан, 2021 елның 1 февраленнән «Мәгълүмат турында» законга үзгәрешләр кертелгән иде. Социаль челтәрләрдә ялган хәбәр таратуга, бер-береңне мыскыллау, сүгенү сүзләре куллануга каршы көрәш турында закон тәүлегенә 500 меңнән артыграк кеше кереп карый торган сәхифә хуҗаларына кагыла. «Гавами челтәр хуҗасы» төшенчәсе дә гамәлгә керде. Үз сәхифәсе, бите булганнарга бурычлар йөкләнә дигән сүз.

Нишләргә?

Тета-коуч, психосоматика буенча белгеч Гөлназ Мирхәлилова интернет мәйданчыкта аноним рәвештә башкаларны мыскыллаудан явызларча файдаланган кешеләрне шартлы рәвештә аерым бер категориягә кертте.

– Нигездә, бу – тормышыннан канәгать булмаган, уңышка ирешә алмаган, эчендә кешеләргә үпкә-рәнҗү хисе йөрткән, башкаларга көнләшеп караган һәм үзбәясе (самооценка. – **Ред.**) түбән дәрәҗәдәге кешеләр. Аларның күңелендә эчке конфликт яши. Бер мисал. Шәхес эш урынында кимсетелүгә дучар, йә булмаса эш шартларыннан канәгать түгел, нәрсәгәдер ирешергә тели, әмма белеме аз, ди. Ул инде башкаларның уңышыннан көнләшеп яши. Проблемасын хәл итә алмау эчке киеренкелек тудыра. Башкаларга яла ягу, нәрсә уйлаганын әйтү – андый кешеләргә эчке ләззәт алу, үзбәясен арттыру мөмкинлеге, – ди белгеч. – Билгеле, бу – ялгыш юл, кешенең үз-үзен алдавы. Башкаларны кимсетү белән үз эчеңдәге проблемаларны чишеп булмый.

Андыйларның корбаны булмас өчен нишләргә соң? Гөлназ Мирхәлилова әйтүенчә, бу хәлдән берәү дә тулысынча сакланмаган.

– Әлбәттә, дөньяда төрле кеше бар һәм аларның фикере дә төрле. Барысының да фикерен якын алмаска өйрәнергә кирәк. Моның өчен бер күнекмә булыша: әгәр дә сиңа интернет киңлегендә начар сүз язалар, кимсетәләр икән, беләп тор: ул синең хакта түгел. Бу сүзләр – аның эчке дөньясы чагылышы. Ул аның никадәр бәхетсез булуын күрсәтә. Игътибарыгызны, энергиягезне аларга сарыф итмәгез. Күңелегез дә тыныч калачак, – дип киңәш итте белгеч.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

САН

Белгечләр әйтүенчә, пандемия башлануга Россиядә интернеттан файдаланучылар саны да, негатив таратучылар да арткан. Узган елгы күрсәткечләргә караганда, илдә яшәүчеләрнең 10 процентына шәхескә карата дорфа сүзләр килеп ирешкән. 7 процентыннан көлгәннәр, 6 проценты кызыксынулары, карашлары, җенесе яисә яшенә бәйле рәвештә мыскыллау белән очрашкан. Сораштыруда катнашучыларның 3 проценты үзенә карата көч куллану, янау сүзләре язуларына тап булган. Интернет кулланучыларының 42 проценты фикеренчә, соңгы биш елда ил күләмендә социаль челтәрләрдә мәсхәрәләүгә корылган язма һәм шәрехләмәләр саны арткан гына.

Россиядә яшәүчеләрнең 22 проценты интернеттагы мыскыллау күренешләре белән күбрәк «ВКонтакте» социаль челтәрендә очраша икән. 18 проценты – «Инстаграм», 13 проценты – «ТикТок», 10 проценты – «Ютуб», 8 проценты «Одноклассники» кебек сәхифәләрдә кибербуллингка юлыккан.

АПАСЫЗ БУЛМЫЙ

МӘКТӘПЛӘРДӘ ЦИФРЛАШТЫРУ ӨЛКӘСЕНДӘ НИЛӘР ҮЗГӘРӘЧӘК?

Татарстанда 2022 ел Цифрлаштыру елы дип игълан ителде. Быел электронлаштыру өлкәсендә мәктәпләрне нинди яңалыклар көтә? Кара тактага, акбурга урын калырмы? Укучылар букча урынына электрон дәреслек кыстырып йөри башламасмы? Өй эшен тикшерүне кайчан компьютерга тапшырачаклар?

Өй эшен компьютер тикшерә

Россия Мәгърифәт министрлыгы мәгарифне цифрлы трансформацияләү стратегиясенең паспортын бастырган. Документта әйтелгәнчә, 2030 елда укучыларның өй эшләрен ясалма интеллект тикшерә башлаячак.

– Укытучылар һәм уку процессында санлы технологияләр нисбәте турында күптән фикер алышу бара. Ясалма интеллект барлыкка килгәч, бәһаләр тагын да артты. Төрле формула, кагыйдә, вакыйгалар һәм башкаларны тикшерүне компьютерга йөкләргә мөмкин. Укытучының төп эше белем бирү булачак. Мәгариф платформаларын исәпкә алсак, Россия моңа әзер, тик мәсьәләнең техник ягы бар. Яхшы компьютерлар һәм элемтә кирәк, – ди академик Виктор Болотов.

Әти-әниләр өчен – мобиль кушымта

Мәктәпләрдәге цифрлаштыру өлкәсе өчен җаваплы белгечләр әйтүенчә, ниндидер яңалык кертү буенча әлегә күрсәтмә юк. Хәер, кемнәндер күрсәтмә көтеп утырырга да кирәкми. Әнә узган уку елында Казанда ачылган «Унбер» мәктәбендә әти-әниләр өчен мобиль кушымта булдырганнар.

– Эшне әти-әниләрдән башладык. Алар өчен бердәм кушымтада мәктәп, билгеләр, укучыларның портфолиосы, өй эшләре турында мәгълүмат булачак. Анда әти-әниләр туклану, белем һәм тәрбиягә бәйле төрле сорауларны бирә алачак. Быел шушы кушымтаны куллануга кертәбез. Икенчесен укытучылар өчен булдырырга җыенабыз. Соңрак укучылар өчен дә барлыкка киләчәк. Заманчалаштырудан калышып булмый. Мәктәп бар яктан алдынгы булырга тиеш. Без бит киләчәк буынны тәрбиялибез. Дәресләрне электрон формада укытмыйбыз, – диде мәктәп директоры Алмаз Хәмидуллин.

Акбур тотып язасы килә...

Иннополис мәктәбендә белем бирүче – «Киләчәк укытучысы» бөтенроссия бәйгесендә җиңгән Айсылу Сәгыйтовадан заманча мәктәп, цифрлы дәресләр турында сораштык.

– Цифрлаштыру – тормышның аерылгысыз өлеше, шуңа күрә аннан өйгә кереп качып, күрмәмешкә салышудан мәгънә бар дип уйламыйм. Әлбәттә, һәр нәрсәнең чиге булырга тиеш. Әгәр теләсә кайсы даруны күбрәк кулласаң, ул агуга әйләнергә мөмкин. Санлаштыру белән дә шул ук хәл. Безгә гаҗәеп мөмкинлекләр биргән цифрлаштыруны файдалы итеп куллана белергә кирәк, – ди рус теле һәм әдәбияты укытучысы Айсылу Сәгыйтова. – Заманча технологияләрне бөтенләй файдаланмау урынсыз булыр иде. Дәресләрдә Лев Толстойның тавышын тыңлый, Есенинга кагылышлы видеоязмалары карый алабыз, теләсә кайсы интерактив музейда була алабыз. Башка мәктәпләрдәге кебек планшет, ноутбук, интерактив такталардан тыш, бездә физика, биологиядән тәҗрибә үткәрү өчен интерактив җиһазлар, Pasco лабораториясе, лазерлы тир, цифрлы микроскоп, метеостанция һәм башкалар бар. Квадрокоптер, тавыш яздыру, видеога төшерү җайланмалары бар. Бездә бар да җитә.

Дөрес, һәр нәрсәнең чиге бар. Белгеч әйтүенчә, укучыларны яңа технологияләрсез дә кызыксындырып була. Дәресне уен рәвешендә оештырып, теләсә кайсы укучыны җәлеп итәргә мөмкин. Ул дәресләрендә еш кына банкага тутырылган шарлар, кубик, карточкалар куллана.

– Укучыларга күңеллерәк тә булып китә әле. Әйтерсең онлайн ресурслардан туеп киткәннәр, бер-берләренең күзенә карап аралашасы, дәрес материалларын тотып карыйсылары килә. Бервакыт миңа бер укучым: «Кайчак акбур белән гади тактага язасы килеп китә», – диде.

Бүген укучыларга клиплы күзаллау хас. Аларга кыска һәм тиз алына торган мәгълүмат кирәк. Моңа шушы заманча технологияләр сәбәпче түгелме?

– Моның төп сәбәбе заманча технологияләргә бәйле түгел. Мәгълүмат ташкыны шулкадәр күп, шуңа күрә кешенең ныклап уйларга вакыты юк. «Ютуб», «ТикТок» кебек кушымталардагы кыска роликлар да проблеманы тирәнәйтә. Бу мәгълүмат шавы онлайн мохитне генә әзәрлекләми бит. Болар – плакатлар, игъланнар, ялтыравыклы журналлар. Олыларда да шундый күзаллау бар. Әмма кыска мәгълүмат башта озак сакланмый, тиз онытыла, – ди Айсылу Сәгыйтова.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Фикер

Сергей КРАВЦОВ, Россия мәгърифәт министры:
– Санлаштыру белемне кысрыклауга китермәячәк. Мәктәптән баш тартып булмый. Укытучы белән укучылар арасындагы элемтәләрне берни дә алыштыра алмый. Дистант формасы кертелгәч, балалар укытучылары янына кайтуны зур түземсезлек белән көтте. Цифрлаштыру мохите ул – мәгариф оешмаларында шартлар булдыру, яңа технологияләр куллану өчен инфраструктура проекты. Заманча дөньяны яңа технологияләрдән башка күз алдына китереп булмый. Мәктәпләрне цифрлаштыру белемне яңарту мөмкинлеге бирә, без моны кулдан ычкындырмаска тиеш. Мәҗбүри дистант яңа технологияләрне үстерү кирәклеген күрсәтте. Балаларны аннан дөрес итеп файдаланырга өйрәтергә кирәк. Мәктәпләр электрон дәреслекләргә күчәргә җыенмый. Электрон әсбапларны санитар нормаларны исәпкә алып кулланырга мөмкин. Әмма тулысынча электрон дәреслекләргә күчү турында сүз алып барылмый. Дәреслекнең кәгазь яки электрон вариантын сайлауны министрлык та, укытучы да түгел, әти-әни хәл итәчәк.

ТАТАРСТАН МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ:
– 2022 елда «Электрон белем бирү Татарстан 2.0» проекты тормышка ашырыла башлый. Ул edu.tatar.ru мәгълүмат системасын яңартуны күздә тота. Проект укытучылар, мәктәп директорларының хезмәтен җиңеләйтүне күздә тота. Татарстан 2022–2030 елларда интернет челтәре, дәүләт мәгълүмат системаларыннан файдалану өчен «Цифрлы мәктәп» стандарты буенча IT инфраструктураны булдырырга субсидия бирелүче төбәкләр исемлегенә кертелде.



2019 елдан республикада «Мәгариф» илкүләм проекты кысасында «Цифрлы белем бирү мохите» проекты гамәлгә ашырыла. Аның максаты – 2024 елга кадәр техниканы яңарту, кадрлар әзерләү, санлы федераль платформа булдыру юлы белән балаларга заманча һәм имин мәгариф мохите кертү. Быел 46 мәктәп һәм 6 урта һөнәри уку йортын ноутбуклар, күпфункцияле җайланмалар белән тәэмин итү күздә тотыла. 2024 елда мондый ярдәм 117 мәктәпкә каралган. Бүген республика мәктәпләренең 80 проценты интерактив чаралар белән тәэмин ителгән.

Шәһәрдән калышмыйбыз

Арча районының Ашытбаш мәктәбендә бүген 79 бала белем ала. Монда ата-аналар җыелышлары, төрле сәбәпләр белән укучылар мәктәпкә килмәгән очракларда дәресләр онлайн уза икән.

Информатика укытучысы Салават Шәйхетдинов әйтүенчә, авыл мәктәбе дә шәһәрнекеннән калышмый, мәктәптә яңа мәгълүмати технологияләр куллану өчен шартлар тудырылган. Бу – заман таләбе. «Дәресләрне заманча ысулларга нигезләнеп алып барабыз. Болай укыту укучыларда кызыксыну уята. Интернетта да укуга бәйле платформалар бик күп. Алар арасында БДИга әзерләнү өчен кирәклеләре дә шактый. Дөрес итеп куллана белергә генә кирәк. Компьютерлар бар, интерактив такталар 1–2 сыйныфта гына җитми. Интернет буенча проблемалар юк», – ди Салават Шәйхетдинов.

Дәресне телефонга калдырсак, ни була?

Әти-әниләр белән узган «туры элемтә»дә Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин һәр нәрсәнең үз урыны булырга тиешлеген әйтте.

– Электрон платформалар күп, алар 30га якын. Аны гына кулланып, дәресне телефонга гына кайтарып калдырсак, нәрсә була? Балалар болай да виртуаль дөньяда яши, үзебез дә сизмәстән шунда кереп китәбез. Хәзер Советлар Союзын гына искә алып, алга барып булмый. Без платформа турында уйлыйбыз. Телефон, интерактив тактада гына реаль тормышны күрмибез. Балалар аралашырга, төрле түгәрәкләргә йөрергә тиеш. Аралашуны бернәрсә белән дә алыштырып булмый. Ни өчен без читтән торып кына укуга күчмибез? Мәктәптә белем алу, туклану, түгәрәкләргә йөрү өчен барлык шартлар тудырылган. Балаларны виртуаль тормыштан аерырга кирәк. Без мәктәптә моны контрольдә тотабыз, ә өйдә – юк. Тәрбиясе турында борчылган әти-әниләр балаларына телефонны озакка бирми. 1 сыйныфта телефонда – 15 минут, югары сыйныфларда 35 минуттан артык утырырга ярамый. Ә бездә көне буе шуннан чыкмыйлар, – диде министр.

Сәрия МИФТАХОВА

17 гыйнвар | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2, ЯКИ КУНАК АШЫ – КАРА-КАРШЫ» 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Семь дней» 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45 «Аулак өй» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Акыл баттл» һәм «Сәйлән» 0+
16.30 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Барыс» – «Ак барс». Прямая трансляция 6+
19.00, 20.00, 01.10 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
00.00 « Соотечественники» 12+
00.25 «Черное озеро». Киллер Подлиза 16+
00.50 «Ватандашлар» 12+
02.00 «Манзара» 6+
02.50 «ТАМАК» 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
07.15, 19.00, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
08.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 6+
09.50 «Яшәргә дә әле, яшәргә». Зөһрә Шәрифуллина концерты 6+
11.00, 15.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
14.00, 02.00 «Ком сәгате» 12+
15.20 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 Хоккей. КХЛ чемпионаты. «Барыс» (Нур-Солтан) – «Ак барс» (Казан) 6+
19.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 01.50, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 Премьера. Анна Банщикова. «ИЩЕЙКА». Новый сезон (S) 16+
23.35 «Познер» 16+
00.40 «ОДНАЖДЫ В ПАРИЖЕ. ДАЛИДА И ДАССЕН» 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.55 «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ» 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
23.35 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.20 Вячеслав Разбегаев, Кирилл Плетнёв, Наталия Быстрова, Анна Гарнова, Андрей Арзяев, Дмитрий Ермак. «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+
04.00 Ярослав Бойко, Анатолий Васильев, Раиса Рязанова, Дарья Повереннова, Илья Соколовский. «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 Профилактика на канале с 06.00 до 10.00 ч.
10.00, 12.30, 15.05, 19.20, 22.35 Новости
10.05 Спец. репортаж 12+
10.25 Зимние виды спорта. Обзор 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.35 Специальный репортаж 12+
12.55 «ДЕСАНТ ЕСТЬ ДЕСАНТ» 16+
15.10 Автоспорт. «Рождественская гонка чемпионов». Трансляция из Тольятти 0+
15.40 «Громко». Прямой эфир
16.55 Хоккей. КХЛ. «Салават Юлаев» (Уфа) – ЦСКА. Прямая трансляция
19.25 Все на Матч! Прямой эфир
19.55 Гандбол. Чемпионат Европы. Мужчины. Россия – Словакия. Прямая трансляция из Словакии
21.35 Все на Матч! Прямой эфир
22.05 Тотальный футбол 12+
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Фиорентина» – «Дженоа». Прямая трансляция
00.45 Все на Матч! Прямой эфир
01.35 «Есть тема!» 12+
01.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Зенит» (Санкт-Петербург) – ЦСКА 0+
03.55 Новости 0+
04.00 «Человек из футбола» 12+
04.30 «Всё о главном» 12+
04.55 «Громко» 12+

НТВ

05.15 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня
08.25, 10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
23.35 «ЗОЛОТОЙ ЗАПАС» (S) 16+
03.00 Их нравы 0+
03.15 «СХВАТКА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.40 «Реальная мистика». «Венок из гибискуса» 16+
07.45 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.50 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.10 «Понять. Простить» 16+
13.15 «Порча». «Сын солдата» 16+
13.45 «Знахарка» 16+
14.20 «Верну любимого» 16+
14.55 «ТЫ МОЯ ЛЮБИМАЯ» 16+
19.00 «БУДЬ ЧТО БУДЕТ» 16+
23.05 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР». 1-я и 2-я серии 16+
01.00 «Реальная мистика» 16+
02.05 «Верну любимого» 16+
02.35 «Порча» 16+
03.00 «Знахарка» 16+
03.25 «Понять. Простить» 16+
04.15 «Тест на отцовство» 16+
05.55 «Домашняя кухня» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «КРЕСТНЫЙ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.20, 18.30 «Спец. репортаж» 16+
09.40 «ВЗРОСЛЫЕ ДЕТИ» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир» 12+
13.25, 14.05 «ЗНАХАРЬ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.50 «Афганистан. Неизвестная война инженерных войск». Док. сериал 16+
19.40 «Скрытые угрозы» 16+
20.25 «Загадки века». Док. сериал 12+
21.15 Новости дня 16+
23.05 «Между тем» 12+
23.40 «ДУМА О КОВПАКЕ» 12+
03.10 «Хроника Победы» 16+
03.35 «ЗНАХАРЬ» 16+

18 гыйнвар | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2, ЯКИ КУНАК АШЫ – КАРА-КАРШЫ» 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Оныта алмыйм...» 0+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45 «Аулак өй» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
17.00 «БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00, 01.30 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Чёрное озеро» 16+
00.00 «Видеоспорт» 12+
00.25 «Соотечественники». Медный колокольчик Амирхана Еники 12+
00.50 «Черное озеро». Убийство профессора 16+
01.15 «Реквизиты былой суеты» 12+
02.00 «Манзара» 6+
02.50 «ТАМАК» 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Ком сәгате» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
07.15, 19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40, 16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
14.00, 02.00 «Ком сәгате» 12+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Тамчы-шоу» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 02.00, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 «ИЩЕЙКА». Новый сезон (S) 16+
22.35 Премьера сезона. «Док-ток» 16+
23.30 «Вечерний Ургант». Лучшее (S) 16+
00.25 «Харджиев. Последний русский футурист» 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.55 «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ» 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
21.20 Русская серия. Максим Аверин. «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
23.35 «Вечер» 12+
02.20 Вячеслав Разбегаев, Кирилл Плетнёв, Наталия Быстрова, Анна Гарнова, Андрей Арзяев, Дмитрий Ермак. «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+
04.00 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.55, 12.30, 15.05, 19.20, 22.35, 03.55 Новости
06.05 Все на Матч! Прямой эфир
09.00 Специальный репортаж 12+
09.20 «ТРИ ДНЯ ДО ВЕСНЫ» 12+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.35 Специальный репортаж 12+
12.55 «ДЕСАНТ ЕСТЬ ДЕСАНТ» 16+
15.10 «МатчБол»
15.40 «СТРИТРЕЙСЕРЫ» 16+
18.00, 19.25 «ОКТАГОН: БОЕЦ VS РЕСТЛЕР» 16+
20.05 «ФАРТОВЫЙ» 16+
22.05 Все на Матч! Прямой эфир
22.40 Футбол. Кубок Германии. 1/8 финала. «Санкт-Паули» – «Боруссия» (Дортмунд). Прямая трансляция
00.45 Все на Матч! Прямой эфир
01.35 «Есть тема!» 12+
01.55 Волейбол. Лига чемпионов. Женщины. «Локомотив» (Россия) – «Дрезднер» (Германия) 0+
04.00 «ЛЕГЕНДА О БРЮСЕ ЛИ» 12+

НТВ

05.20 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня
08.25, 10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
23.35 «ЗОЛОТОЙ ЗАПАС» (S) 16+
03.05 Их нравы 0+
03.25 Детектив «СХВАТКА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.35 «Реальная мистика» 16+
07.35 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.35 «Давай разведёмся!» 16+
09.45 «Тест на отцовство» 16+
11.55 «Понять. Простить» 16+
13.00 «Порча». «Убийца» 16+
13.30 «Знахарка» 16+
14.05 «Верну любимого» 16+
14.40 «БОЙСЯ ЖЕЛАНИЙ СВОИХ» 16+
19.00 «НАРИСУЙ МНЕ МАМУ» 16+
23.05 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР». 3-я и 4-я серии 16+
01.05 «Реальная мистика» 16+
02.10 «Верну любимого» 16+
02.35 «Порча» 16+
03.00 «Знахарка» 16+
03.25 «Понять. Простить» 16+
04.15 «Тест на отцовство» 16+
05.55 «Домашняя кухня» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «ЗНАХАРЬ». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.25 «С ТОБОЙ И БЕЗ ТЕБЯ...» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир» 12+
13.25, 14.05 «ЗНАХАРЬ». 5-я – 8-я серии 16+
14.00 Военные новости 16+
18.30 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Афганистан. Неизвестная война инженерных войск». Док. сериал. 2-я серия 16+
19.40 «Легенды армии». Виссарион Григорьев 12+
20.25 «Улика из прошлого» 16+
21.15 Новости дня 16+
23.05 «Между тем» с Наталией Метлиной. Премьера! 12+
23.40 «ДУМА О КОВПАКЕ». Фильм 3-й 12+
02.30 «Еж против свастики» 12+
03.10 «Хроника Победы». Док. сериал 16+
03.40 «ЗНАХАРЬ». 5-я и 6-я серии 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 17 – 23 ГЫЙНВАР

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Хисләрегезне биктә тота алмассыз... Яратасыз икән – белгертегез! Эштә ихлас булсагыз әйбәт. Хаталансагыз, бу хакта җитәкчегезгә әйтүдән курыкмагыз. Намуслылыкны, һичшиксез, исәпкә алачак ул.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Моңа кадәр күренмичә килгән талантыгыз әйбәт кенә керем китерә башлар. Бу чорда ирештерелгән тәкъдимнәрне, ике дә уйламастан, кабул итегез. Өлкән буын белән аралашканда, сүзгә саграк булыгыз: үзегезне аңламаулары аркасында үпкәләшү ихималы бар.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Әҗәткә сорап торсалар, баш тарту әйбәт. Шул сәбәпле үзегез авыр хәлдә калырга мөмкинсез. Атна азагында баштанаяк эшкә чуму көтелә. Өйдәгеләргә калып эшләү сәбәпләрен аңлатырга туры килер...

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Атнаның беренче яртысында максатыгыздан ераклаша барасыз кебек тоелыр. Ни хикмәт: тырышыбрак эшләгән саен нәтиҗәсе начаррак булыр. Ләкин артыгын хафаланасы юк: дустыгызның бик вакытлы ярдәм кулы сузуы хәлегезне бермә-бер җиңеләйтер.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Бу көннәрдә күңелегезгә хуш килүче кешеләр белән янәшә булырга тырышыгыз. Хуш килмәгәннәрен читкәрәк тибәрегез. Атна ахырында матди якка уңай тәэсир итәрдәй хәлләр килеп чыгасын көтегез.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Хезмәт урынында өстәмә бурычлар алмагыз. Бер тапкыр ризалашсагыз, башкаларның эшен гел өеп кенә торулары бар... Ялгызларның гомерлек парларын табу ихтималы бик зур.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Атнаның беренче яртысында сәламәтлеккә игътибарлырак булу кирәк. Ел башында эштәге киеренкелек организмны инде алҗытырга да өлгергән шул... Аның каравы ял көннәре бик зур күтәренкелектә узачак – бердәнберегез искиткеч матур бүләк ясаячак, дусларыгыз өметле хәбәрләр белән сөендерәчәк.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Беренче адымны ясаудан курыкмагыз. Тормышыгызның барлык өлкәләренә кагыла бу! Атна ахырында шәп кенә сюрпризлар көтегез. Тик үзегезне бәхетле итүчеләргә рәхим-шәфкатьле, рәхмәтле була белегез.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Өйгә эш күтәреп кайтмагыз – якыннарыгыз үзегезне аңламаска мөмкин. Шуңа күрә барысын да эш сәгатьләрендә башкарып куярга тырышыгыз. Атна уртасында акчага бәйле «баш авырту» килеп чыгарга мөмкин.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Бу чорда кабул кылган карарларыгыз тормышыгызны тамырдан үзгәртеп куярга мөмкин. Әмма йолдызлар ашыкмаска, барысын да яхшылап уйларга киңәш итә. Иҗат кешеләре өчен искиткеч шәп чор.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Хезмәттәшләрегез белән аралашканда, ниндидер кыенсыну сизәргә мөмкинсез. Сәбәбе – үзегезгә барып ирешкән гайбәт сүзләре бугай. Борчылмагыз: кайбер көнче адәмнәрнең оятсыз кыланмышы гына бу. Озакламый барысына да ачыклык кертелер һәм үзегезгә иркен сулап кую мөмкинлеге ачылыр.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Тәкъдимнәргә бик сак булыгыз. Ялгышмас өчен башта күпне белгән кешеләр белән киңәшләшегез. Яңа ел курантлары суккан вакытта әйтелгән теләкләрнең тормышка аша башлавын сизеп сөенерсез.

КАТНАШ АЗЫК, АШЛЫК САТАМ.
Йомырка салучы тавыклар өчен катнаш азык

800 сум
Адрес:
Казан, Техническая урамы, 15.
Телефон:
8 (927) 049-97-06
Реклама

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

ЧӘЙ ЙОКЫНЫ КАЧЫРА

Кеше гомеренең өчтән бер өлешен йоклап уздыра, ди галимнәр. Татлы йокы бик күп төрле авыруларны кисәтә, иммунитетны ныгыта. Бүген бик күпләр шул бәхеттән мәхрүм. Рәсми саннарга ышансаң, ил халкының 23 проценты йокысызлыктан интегә. Йокысызлыкны ничек булдырмаска? Татлы йокы сере нидә?

pixabay.com

КФУның Университет клиникасының табиб-сомнологы Лилия ШАҺИӘХМӘТОВА белән шул хакта сөйләштек.

:: Лилия Ядкәровна, йокысызлык ничек башлана?

– Йокысызлык ул – йокы бозылу. Кеше, ким дигәндә, бер-ике сәгать дәвамында йокыга китә алмый тилмерсә, бу инде йокысызлык санала. Норма буенча кеше 15–20 минут эчендә йокыга китәргә тиеш. Вакытында йокыга талып, төнлә уянып, йоклый алмыйча яткан кешеләр дә бар. Бу – шулай ук йокысызлык диагнозы. Алты сәгатьтән азрак йоклаган кешенең дә йокы режимы бозыла.

:: Йокысызлык сәбәбе нидә?

– Хәзерге вакытта 60–70 төрле авыруның йокысызлыкка китерүе расланган. Әмма араларында йокысызлыкка китергән иң төп сәбәп булып стресс санала. Көндәлек режимы дөрес булмаган, ягъни еллар дәвамында көн саен төрле вакытта йокларга ятып, төрле вакытта уянган кешеләр дә, ахыр чиктә, йокысызлыктан тилмерә башлый. Йоклаганда гырлау да йокысызлыкка китерә ала. Билгеле булганча, кеше гырлаганда аның бер мизгелгә сулышы тукталып тора (апноэ). Шул сәбәпле, ун сәгать йокласа да, аның йокысы туймый, арыганлыгы бетми.

:: Йокысызлык билгеле бер чир турында алдан белгертә аламы?

– Әйе, алай да була ала. Альцгеймер, Паркинсон кебек аерым бер психик, неврологик авырулар нәкъ менә йокысызлыктан башланырга мөмкин.

ЙОКЫСЫЗЛЫКНЫ БУЛДЫРМАУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

- көндәлек тормышыбызда стресслардан котылып булмый. Әмма без аларны дөрес итеп кабул итәргә өйрәнә алабыз. Моңа төшенгән кешене йокысызлык кебек афәт борчымаячак;
- йокы режимын җайга салырга онытмагыз. Кеше көн саен бер үк вакытта йокларга ятып, бер үк вакытта торырга тиеш;
- йоклар алдыннан кәһвә, энергетик кебек эчемлекләр кулланырга ярамый. Хәтта чәй эчәргә дә киңәш ителми. Ник дигәндә, чәй составында кофеин бар. Ул исә – йокының дошманы. Шуңа күрә бу эчемлекләрне көннең беренче яртысында гына куллану хәерле. Төштән соң аларны сок, морс, гади су, үлән төнәтмәләренә алыштырырга тырышыгыз;
- йокысызлыктан интеккән кешеләргә начар хәбәрләрне дә сирәк тыңларга кирәк. Йөрәккә якын алмыйм дисәң дә, алар барыбер баш миендә тупланып бара, үз чиратында йокыга йогынты ясый;
- йокларга 1–1,5 сәгать кала телефон, гаджетларны сүндереп, читкә алып куярга кирәк;
- йоклар алдыннан китап укырга ярый. Ләкин ул ярсыта, елата, борчуга сала торган әсәр булмаска тиеш.

:: Сезгә йокысызлыктан зарланып мөрәҗәгать итүчеләр күпме?

– Соңгы арада андыйлар аеруча күбәйде. Бу коронавируска бәйле. Беренчедән, бу вирус үзе үк – зур стресс. Аның турында көн дә ишетергә туры килгән хәвефле хәбәрләр аркасында, бу чир белән авырмаган кеше дә стресска бирешергә мөмкин. Тагын шунысы да бар: ковид нейровирус санала. Ул турыдан-туры нерв системасына, баш миенә тәэсир итә. Соңгысының ис, тәм сизә торган өлешләреннән тыш, йокы өчен җаваплы өлешләренә дә тискәре йогынты ясый ул.

:: Өлкән яшьтәгеләрнең күбесе төнлә начар йоклавыннан зарлана. Бу күренеш нәрсә белән аңлатыла?

– Өлкәннәрнең буш вакыты күп. Иртүк торып, эшкә барасы юк. Шуңа күрә кайчан тели – шул вакытта йокларга ята, уяна ала. Көндез дә черем итеп алалар. Физик активлык җитмәү дә өлкәннәрнең йокысызлыктан интегүенә сәбәпче булырга мөмкин. Аннары яшь барган саен баш миенең йокы өчен җавап бирә торган өлешләре дә үзгәреш кичерә. Тормыштагы бертөрлелек, эмоцияләр җитмәү дә еш кына йокысызлыкка китерә.

:: Туклануыбыз йокыга йогынты ясыймы?

– Фәлән продукт йокыны яхшырта дигән фәнни дәлилләр юк. Шулай да кич белән банан ашап куйсаң, бал салынган җылы сөт эчсәң, йокың тәмле була дигән ышану яши. Моны фәнни яктан да аңлатып була, билгеле. Аларда триптофан дигән аминокислота бар. Ул йокыны китерүче мелатонин гормонының башлангычы санала.

:: Йокысызлыкны өй шартларында дәвалап буламы?

– Әйткәнемчә, йокысызлык бик күп сәбәпләр, аерым алганда, чирләр аркасында килеп чыга. Аның нәрсә аркасында да пайда булганын төгәл ачыкламыйча, йокысызлыктан котылып булмый. Әгәр аңа стресс кына сәбәпче икән, кеше, үзен кулга алып, йокы режимын җайга сала ала әле. Әгәр йокысызлык җитдирәк чиргә бәйле пайда булса, иң элек әнә шул авыруны дәваларга кирәк. Шуңа күрә монда табиб ярдәменнән башка булмый.

Абау!

Бәдрәфтән дә пычраграк

Компьютерда эшләдеңме – кулыңны ю! Британия галимнәре әнә шундый киңәш бирә. Баксаң, кайбер компьютерларның клавиатуралары җәмәгать бәдрәфләреннән 400 мәртәбәгә пычраграк икән. Галимнәр әнә шуны исәпләп чыгарган. Компьютерның иң пычрак урыннары дип клавиатура белән «тычкан»ны атый алар. «Шуңа күрә, сәламәтлеккә зыян килмәсен өчен, аена бер тапкыр булса да, компьютерыгызны чистартыгыз. Ә клавишаларны исә, елга бер тапкыр булса да сөтеп, сөртеп, яңадан җыярга кирәк», – дип киңәш итә белгечләр.



Үзем сынадым

Аяк тирләп интектерсә

Иремнең аягы бик каты тирли. Соңгы арада бер ысулның файдасын күрә башладык. Сезгә дә язып әле. Башта 2 литр суда 2 төймә фурацилин эретергә кирәк. Шул суга аякларны 10 минут тыгып утырасың. Аякларны судан алгач, сөртмәскә кирәк, алар үзләре кибәргә тиеш. Шуны көн дә эшли башлагач, файдасы сизелә башлады.

Гөлфия М. Балтач

ВИНОГРАД ЯМАН ШЕШНЕ КИСӘТӘ

Табиблар көн саен 150дән алып 250 граммга кадәр виноград ашарга киңәш итә. Анда иммунитетны ныгыта торган антиоксидантлар күп, ди белгечләр. Кара виноградта алар аеруча күп. Виноградның моннан тыш та файдалы үзлекләре бихисап.

- Виноград составындагы үсемлек эстрогеннары төркеменнән булган ресвератрол дип аталган матдә күзәнәкләргә зыян китерә торган кушылмаларга каршы көрәшергә сәләтле;
- ул холестерин күләмен киметә, кан тамырларында ялкынсынуны баса;
- виноград – бик яхшы витаминнар чыганагы. Виноград төшендә булган A, E һәм K витаминнары, шулай ук табигый май күзәнәкләрне ныгытуга һәм яшәртүгә ярдәм итә;
- йөрәк-кан тамыры авыруларыннан саклый, составындагы кофе кислотасы, кверцетин һәм мирицетин кебек фенол тоташтыргычлар организмны онкология авыруларыннан да саклый;
- виноград сәламәтлек өчен файдалы булган башка үзлекләргә дә ия. Анда целлюлоза, шикәр һәм кислоталар катнашмасы табигый йомшарткыч булып тора;
- аның составындагы минераллар теш һәм сөякләрне ныгытырга булыша.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ШӘХСИ ЙОРТМЫ, ӘЛЛӘ ФАТИРМЫ?

Узган ел бәяләре кискен артса да, торак сатып алучылар саны кимемәгән, ә киресенчә, арткан гына. Быел да узган елгыдан ким булмас, дип фаразлый белгечләр. Моны торак базарында ихтыяҗның тәкъдимнәргә караганда артыграк булуы белән аңлата алар. Шулай да торак сатып алганда нәрсәне истә тотарга? Ничек алданмаска? Фатир алыргамы, әллә шәхси йортмы?

Әлеге сорауларга риэлтор Айгөл ҖӘЛӘЕВА белән җавап эзләдек.

:: Айгөл, торак сатып алганда, фатир алыргамы, әллә шәхси йортмы, дигән сорау белән мөрәҗәгать итүчеләр булмый калмыйдыр. Аларның уңай һәм тискәре якларын барлаганда нәрсәгә игътибар итәргә?

– Шәхси йорт яки фатир алу клиентларның ихтыяҗларын күздә тотып эшләнә. Кем өчендер йортның, ә кем өчендер фатирның өстен булуы мөмкин. Үз йорты белән яшәүчеләр өчен юл мәсьәләсе беренче урында тора. Чөнки шәһәрнең үзендә шәхси секторлар бик күп түгел. Шәхси йортлар, гадәттә, шәһәр читендә төзелә. Димәк, үз йорты белән яшәү шәһәргә бәйле булмаган гаиләләр өчен яхшы, анда ыгы-зыгы азрак, һава экологик яктан чиста, бүлеп алынган үз җирең була. Әгәр көн саен шәһәргә барып йөрергә кирәк булса, гаиләдә транспорт булу зарур. Шулай ук эшкә, уку йортына кадәр барып җитү вакытын исәптә тотарга кирәк. Беренче чиратта мин үз клиентларыма, күңелегезгә ошаган вариантны сайлагыз, дим. Чөнки яраткан йортыбызга яки фатирыбызга без көн саен әйләнеп кайтабыз. Анда без гаиләбез белән үзебезне рәхәт хис итәргә, энергия тупларга тиешбез. Фатир яки йорт сайлаганда, беренче чиратта, сатып алына торган объект буенча документларны карарга кирәк. Сүз яңа торак турында гына түгел, ә кулдан (икенчел базардан) сатып алу турында да бара. Шулай ук бу торак йортка да кагыла, әлеге җир кишәрлегендә торак йорт төзүне чикләү юкмы икәнлеген белеп тору зарур.

:: Фатир яки йорт сатып алганда килешүдә торак бәясен киметеп күрсәтү очраклары еш очрый. Дөрес бәяне күрсәтмәү нәрсәсе белән куркыныч?

– Күчемсез милек сатканда һәм алганда аның тулы бәясен күрсәтү мәҗбүри. Бәясен киметеп сату сатып алучыга да, сатучыга да мәшәкатьләр тудырырга мөмкин. Мондый очракта сатучы өчен салым хезмәтеннән зур күләмдәге штраф яный, ә сатып алучы бөтенләй торaксыз калырга мөмкин.

:: Торак базарындагы бәяләргә килгәндә беренчел торак алу файдалымы, әллә икенчел торак бәя ягыннан отышлырак чыгамы?

– Монда шулай ук барысы да сатып алучының ихтыяҗыннан тора. Яңа торак алуга килгәндә, күпләрне алда торган ремонт өчен чыгымнар куркыта. Күпләр яңа торакта яшәргә теләсә дә, әзер торакны сайларга мәҗбүр була. Үз тәҗрибәмнән чыгып әйтәм, торак сатып алучыларның 85 проценты үзләренә фатир яки йортны ипотека кредитына ала. Монда һәркемгә үз керемнәреннән чыгып хәл итәргә кирәк. Соңгы елда беренчел базарда бәяләр сизелерлек артты. Кичектерелгән ихтыяҗ, дәүләт программасы, төзүчеләрнең банклар белән бергә бирә торган субсидияләре, ә 2021 елның икенче яртыелыгында төзелеш материалларына ихтыяҗның кискен артуы бәяләр үсүгә китерде. Хәзерге көндә Казанның беренчел торак базарында бер квадрат метр бәясе икенчел базарга караганда югарырак. Тик юридик заттан фатир сатып алганда, түбән процент ставкасы буенча ипотека рәсмиләштерергә була. Дәүләт программасы, гаилә ипотекасы ярдәмендә кредит буенча айлык түләүләр йөкләнешен киметергә мөмкин. Хәзерге вакытта икенчел базарда процент ставкасының артуы күзәтелә, шул рәвешле банктан алырга мөмкин булган акча «кыймммәткә» төшә. Ә 2022 елда торакның квадрат метры бәясен вакыт күрсәтер. Казан – миллионлы шәһәр, анда яшәргә уңайлы, шул исәптән сатып алучылар тарафыннан инвестицион ихтыяҗ да бар, ә ихтыяҗ булганда бәяләр төшмәячәк.

pixabay.com

15 елга 3 миллион сум кредит алган очрак (Якынча бәяләр)

Ипотека төре	Айлык түләү
Гаилә ипотекасы[1]	20000
Стандарт дәүләт программасы[2]	26000
Икенчел торак	31000

[1] Гаилә ипотекасы 2018 елның беренче гыйнварына кадәр беренче яки аннан соңгы балалары туганнарга бирелә.

[2] Дәүләт программасы буенча теләсә кем торак алырга мөмкин, тик монда бер шарт – кредит күләме 3 миллион сумнан артмаска тиеш.

Белеп тор!

КУЛГА ШЫРПЫ КЕРСӘ

Кулга шырпы кергән икән, аны дөрес итеп ала белү кирәк.

1 Кечкенә косметик пинцетны антисептик яки спирт эремәсе белән эшкәртергә.

2 Тире астына кергән шырпының очын пинцет белән эләктерергә. Әгәр күренми икән, лупа белән карап табарга. Тик шырпы кергән урында тирене кысмагыз, ул, киресенчә, тирәнрәк керергә мөмкин.

3 Тире астына кергән шырпыны почмак ясаган уңайга тартыгыз.

4 Шырпыны алганнан соң әлеге урынны дезинфекцияләгез, ә өстенә пластырь ябыштырыгыз.

Орхидея сарымсак ярата

Орхидея еш һәм шаулап чәчәк атсын өчен аны сарымсак белән туклaндырырга кирәк икән! Ул чәчәкнең тамыр системасын ныгыта, бактерияләрдән саклый.

Орхидеяга «тәмлүшкә» ясау өчен 5 зур яки 6–7 ваграк теш сарымсак, ике стакан су (500–600 мл) һәм ярты төймә янтарь кислотасы кирәк. Янтарь кислотасын җылы суда эретеп, аңа изелгән сарымсак салып, пыяла савытта бер тәүлек тотарга. Аннары әлеге катнашманы зуррак савытта 2 стакан су белән болгатып, анда орхидеяны савыты белән утыртырга кирәк. Ике сәгатьтән орхидеяны гөл чүлмәгеннән әлеге катнашмадан алып үз урынына куярга мөмкин. Ә берәр айдан ул сезне чәчәкләре белән куандырыр.

Тәмле булсын!

«Помадка»

Тамада Чулпан Гарипова рецепты:

– Безнең балачак конфеты бу. Ул вакытта конфет булмаганнан кайната иделәр. Помадка дип тә атыйлар кайбер якта. Мин балачактагы рецепт буенча кайнаттым. 1:3 исәбеннән ясала. Ярты литр сөткә өч ярты литрлы банка белән шикәр комы салырга һәм болгата-болгата сүрән утта кайнатырга кирәк. Кашык авырaеп, зур-зур тишекләр хасил булып кайный башлагач, 50 грамм атланмай кушып да майлаган табага салдым. Бөтенләй катып беткәнче ромбиклар сызып чыктым. Каткач, шул эздән бик җайлы гына сындырып булачак.

Исеңдә тот!

ТЕШЛӘРНЕ АГАРТАБЫЗ

3 процентлы водород перекисен 1:2 исәбеннән чәй содасы белән болгатырга. Әлеге паста сыман катнашма белән тешләрне 1–2 минут чистартырга һәм яхшылап су белән чайкарга кирәк. Әлеге катнашманы атнага бер тапкыр кулланырга мөмкин.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА әзерләде

ЗӘХМӘТЛЕ УРЫН – ҖЕН ЙОРТЫ

Зәхмәт, зәхмәт кагылу, зәхмәтле урын... Көндәлек тормышта бу сүзләрне, еш ук булмаса да, шактый ишетергә туры килә. Зәхмәтне бозым белән бутаучылар да очрый. Алар үзара ничек аерыла? Зәхмәт кагылу нәрсәсе белән куркыныч?

Бу сораулар белән «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт ХӘЙРУЛЛИНга мөрәҗәгать иттек.

:: Рөстәм хәзрәт, иң элек зәхмәт диган төшенчәгә ачыклык кертеп китегезче.
– Зәхмәт – җен-пәриләр белән бәйле төшенчә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Сөякләр, пычрак ул – җен-пәриләрнең ризыгы», – дигән. Шуңа күрә сөяк, юынтык сулар ташланган урыннар зәхмәтле санала. Биредә җеннәр яши дигән сүз. Шуңа күрә урамнан барганда юлда, әйтик, шул ук сөякнең аунап ятканын күрсәң: «Әгузү билләһи-минәш-шәйтанир-раҗим», – дип, аны чүплеккә алып салырга кирәк.

:: Тагын кайсы урыннар зәхмәтле санала?
– Сөяк, юынтык сулар ташланган урыннардан тыш, мәет юган су ташланган җир, элеккеге мунча нигезе, мал чала торган, юл фаҗигасе килеп чыккан урыннар да зәхмәтле санала.

:: Зәхмәтле урында егылсаң, ни эшләргә?
– Андый чакта: «Әгузү билләһи-минәш-шәйтанир-раҗим», – дип, ул урынга өч тапкыр төкерергә кирәк.

:: Бервакыт бер авыру ир-атның вакыт-вакыт саташып алуын «аңа зәхмәт кагылган, шуңа шундый» дип аңлатканнар иде. Имеш, берничә ел элек зәхмәтле урынга егылган булган. Зәхмәт кагылу, дөрестән дә, кеше язмышын үзгәртә аламы?
– Әйе, алай да булырга мөмкин. Зәхмәтле урында яшәгән җеннәр шушы урынга туры килгән кешенең эченә кереп оялый ала. Шул рәвешле алар адәм баласыннан үч ала. Чөнки җеннәр зәхмәтле урынга баскан кешене аларның тынычлыгын алган, өйләрен тар-мар китергән дошман кебек кабул итә. Зәхмәт кагылган, ягъни эченә җен кереп урнашкан кеше ачулана, үз-үзен кулда тота алмый башлый, күңел төшенкелегенә бирелә, табиб бусагасын күпме генә таптаса да, чирен таба алмыйлар. Ул хәтта саташа башларга да мөмкин. Шул рәвешле аның үз-үзен тотышы гына түгел, язмышы да үзгәрә. Кеше эченә кереп оялаган җенне чыгару өчен аны яхшылап өшкерергә кирәк.

:: Зәхмәт бозымнан нәрсәсе белән аерыла?
– Зәхмәттә без үзебез гаепле. Әйткәнемчә, без җеннәргә зыян китерәбез, шуңа җәзасын да алабыз. Бозым исә башка кеше тарафыннан ясала. Ул сихерчегә бара да, фәлән кешегә зыян салуны сорап, бозык ясаттыра.

:: Зәхмәттән котылып буламы? Аннан ничек сакланырга?
– Котылып була. Зәхмәттән арыну өчен кешене өшкертергә кирәк. Аннан саклануга килгәндә, әгәр без тәһарәтле, гөселле булсак, намаз укып, дога кылсак, берниндн зәхмәт тә янамый. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә: «Бу кешегә бернәрсә дә зыян китерә алмас», – дигән.

Бер хәдис уңаеннан

Пәйгамбәребез: **«Кечкенәләребезгә мәрхәмәт итмәүчеләр вә олыларыбызның хакларын белмәүчеләр бездән түгел», – дигән.**
«Өммәтләр югары күтәреләләр вә түбән төшәләр, алга китәләр вә артта калалар, хуҗалык итәләр, хезмәтче булып йөриләр, шушы эшләрнең һәрберсендә төп этәргеч – яшьләр.
Өммәтләрнең түбән китүләре үтәлергә тиеш булган гыйбадәт вә вазыйфаларны башкармауларыннан башлана. Мондый халыклар соңрак дин хакында әдәпсезлек күрсәтәләр, тәрбиясез сүзләр сөйлиләр, никах вә өйләнүгә әһәмият бирмиләр, гаилә хөрмәтен сакламыйлар. Бозыклыкка биреләләр вә шуның сәбәпле һәртөрле хасталыкларга дучар булалар. Шулай итеп, бозык яшьләрдән бозык бер милләт туа. Әмма төзек вә фазыйләтле яшьләрдән төзек вә фазыйләтле бер милләт хасил була.
Шуның өчен яхшы вә әхлаклы яшьләр җитештерергә кирәк. Болар олыларның хакларын да ихтирам итә белерләр, милләтне дә тәрбия кылырлар.
Яшь вакытта яхшы тәрбия алмаган кешенең тәрбия күрү нияте белән шәехләргә йөрүләре, тәкъва вә суфи булып күренүләре кеше алдау булмаса да, күп вакытта үз-үзен алдаудан башка булмас. Тәрбиянең асыл чоры – картлык түгел, бәлки яшьлек заманы. Яшь вакытында нинди генә рәвештә бөгелгән чыбыкны картайганнан соң бөгү – сындырудыр.
Һәрхәлдә, бу хәдис – шәриф мөселманлыкның гына түгел, бәлки инсанлыкның да мизаны. Кечкенәләргә хөрмәтсез, олыларга ихтирамсыз булган кешеләрне мөселман сыйфатында күрү мөмкин булмаса, инсан сыйфатында күрү дә мөмкин булмас». (Риза Фәхретдин. «Җәвамигуль Кәлим шәрехе». 245 нче хәдис.)

Тынычлык кыйссасы

Бервакыт сәүдәгәр кибеттә бик кадерле сәгатен югалткан. Бүлмәнең бөтен почмакларыннан эзләсә дә, аның эзенә төшә алмаган. Кәефе кырылган ир урамнан узып барган бер төркем кешегә игътибар иткән. Сәгатьне тапкан кешегә зур акча вәгъдә итеп, аларны югалган әйберне эзләшергә чакырган. Тегеләр исә, шатланып, сәгать эзләргә керешкән. Күне буе маташканнар, кибетнең астын өскә китергәннәр – нәтиҗәсе генә булмаган. Ир сәгатьне табачагына бөтенләй өметен өзгән.
Шунда аның янына 5 яшьлек бер малай килеп баскан. Сәгатьне эзләшергә килүен әйткән ул. Сәүдәгәр исә кул гына селтәгән. Синнән дә олырак абый-апаларың да таба алмады инде аны, янәсе. Шулай да малайга, кибеткә кереп, эзләп карарга рөхсәт иткән ул. 5 минут та үтмәгән, малай югалган сәгатьне табып алып чыккан. Сәүдәгәрнең күзе дүрт булган. Гаҗәпләнүен яшермичә:
– Бер төркем кеше көне буе эзләп тә таба алмады. Син ничек биш минутта таптың моны? – дип сораган ул малайдан.
Малай исә:
– Мин кибеткә кердем дә тыныч кына утыра бирдем. Шунда каяндыр сәгать тавышы ишетелде. Шул якка борылып карасам, анда югалган сәгать ята иде, – дигән.
Тормышта да шулай: нинди-дер катлаулы мәсьәләне хәл итү өчен чәчкә ябышып, хәвефләнеп, арлы-бирле чабышасы урынга, кайчак әнә шушы малай кебек тыныч кына утырып, йөрәгеңне тыңларга кирәк. Әлле нинди төеннәрне дә чишәргә, юл күрсәтергә сәләтле ул!

Эшләр уңсын өчен укыла торган дога

«Аллаһуммә инни әсъәлүкә хайра мә фи һәзәл яум вә хайра мә бәгъдәһү вә әгузү бикә мин шәрри мә фи һәзәл яум вә шәримә бәгъдәһү».
Мәгънәсе: «И, Раббым, мин Синнән бу көннең изгелекләрен сорыйм. Бу көндә булачак барча бәла-казалардан мине коткарсаң иде. Барча булган бозыклыктан, зарардан мине саклансаң иде. Шушы көндә генә түгел, башка вакытта да миңа барча изгелекләреңне ирештерсәң иде. Бүген һәм башка көннәрдә дә мине бәла-казадан сакласаң иде».

МӨСЕЛМАННАР ӨЧЕН ТЫРНАК КИСҮ ТӘРТИБЕ

«Тухфатуль әбрар» китабында шулай язылган: «Тырнак болай алына: уң кулының имән бармактан башлап чәнчә бармаккача, аннары сул кулы чәнчә бармактан баш бармакка хәтле. Ахырдан уң кул баш бармагы тырнагы киселә. Аяк тырнаклары уң аякның кечкенә бармагыннан башлап сул аягының кечкенә бармагында тәмамлана».
«Шәрхи әврад»та шулай диелгән: «Тырнакны көндез дә, төнлә дә алырга була, чөнки хәерле эшне кичектереп булмый. Әгәр тырнак үскән булса, җомганы көтәргә кирәк түгел. Алынган тырнакны күмү яхшырактыр. Чәчне, тырнакны җөнүб вакытта алу мәкруһтыр. Кендек асты төкләрне тартып алу мәкруһтыр. Култык астындагын кыру да ярыйдыр».

➤Дүшәмбе көн тырнак кисәр булса, ул кешедән диваналык китәр, сихәт табар.
➤Сишәмбе көн тырнак кисәр булса, ул кешенең саулыгы китәр, чир килер.
➤Чәршәмбе көн тырнак кисәр булса, ул кешедән шайтан вәсвәсәсе китәр, куркыныч килер.
➤Пәнҗешәмбе көн тырнак кисәр булса, Ходай каршында бурычлы булыр.
➤Җомга көн тырнак кисәр булса, ул кешенең языклары китәр, рәхмәткә ирешер.
➤Шимбә көн тырнак кисәр булса, ул кешенең зәхмәте китәр, сихәт табар.
➤Якшәмбе көн тырнак кисәр булса, ул кешедән байлык китәр, дәрвишлек килер.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ЛЭЙНА:
«БӨТЕН КЕШЕ ДӘ ТӘРТИПЛЕ ҺӘМ ДӨРЕС БУЛЫП БЕТӘ АЛМЫЙ»

«Ни хәл?» сәхифәсенең бүгенге кунагы кыю һәм үзенчәлекле образы белән күпләрнең мәхәббәтен яулаган һәм шул ук вакытта еш кына тәнкыйть сүзләре ишеткән ЛЭЙНА. Җырчының нинди яңалыклары бар? «Йолдыз чире» йоктырганнарга ул нинди киңәш бирә? Үзен «маймыл» дип атаучыларга кыз ни дип җавап бирә?

:: Ни хәл?
– Бар да яхшы, рәхмәт! Әле менә ике җыр әзерлибез, клиплары белән бергә гыйнвар аенда дөнья күрер дип ниятләп торабыз. Шуларның берсенә ике төрле клип әзерлибез. Минем Төркиядә белем алучы, режиссер һөнәрен үзләштерүче бер дустым бар. Клипларның берсен ул төшерәчәк. Төркия сериалларына мөкиббән мин, шуңа да үз клибымда әлеге ил кешеләре булу минем өчен зур шатлык булды.

:: 2022 елга нинди кәеф белән аяк бастың?
– Кәеф шәп! Яңа елны Казанда каршы алдым. Әти-әнием дә янымда иде. Рәхәтләнеп авыл ите ашадым *(көлә)*. Елларда эш турында бик уйламадым. Якыннарым, дусларым белән очраштым, кыскасы, рәхәтләнеп ял иттем. Хәзер менә ныгытып эшкә тотынырга кирәк. Әйткәнемчә, яңа җырлар әзерлибез, концертлар да көттермәс, тиздән башланыр.

:: Яңа ел төнендә «ТНВ» каналында син төп рольне башкарган мюзикл күрсәттеләр. Әлеге проект үзеңә ошадымы?
– Театр юнәлеше буенча белем алгач, үземне актер буларак та күрсәтү турында хыяллана идем. Дөрес, клипларда да син нинди дә булса роль башкарасың, әмма фильмда уйнау, бигрәк тә төп рольне башкару – башка нәрсә.

Дөресен генә әйткәндә, төшерү процессы башланганчы, бу эшне тиз генә башкарып чыгарбыз дип уйлаган идем. Нибары ике сәгатьлек фильм, имеш. Ләкин съемкалар бик озакка сузылды, әллә ничә дубль ясадык. Мактанып әйтүем түгел, әмма кисәтүләрнең иң азы миңа эләкте. Бәлки, тормышка якын итеп уйнарга тырышуымның нәтиҗәсе булгандыр. Артыгын кыланасым килмәде. Лэйләнең хис-кичерешләре – ул минем дә хис-кичерешләр.

:: Ул мюзикл турында фикерләр күп һәм төрле булды.
– Әйе, әнием дә шулай диде. Мин аларны үзем укымыйм, ә ул бик борчыла. Игътибар итмә, дип күпме әйттем югыйсә. Һәр кешенең үз фикере булырга тиеш. Ошатырга яки ошатмаска хакы бар. Минем эш үз ролемне башкарып чыгу иде һәм мин аны 100 процентка башкарып чыктым дип саныйм, ә калганы мөһим түгел.

Бозаулаган сыерны тикшереп карау җиңелрәк. Аны, һичшиксез, савып карап алырга кирәк. Саудырамы, имчәкләре уңайлымы, холкы тынычмы? Бу вакытта шул сорауларга җавап табарга була. Саугач, җиленнең арткы өлешендә җыерчыклар барлыкка килү сыерның сөтле булуын күрсәтә. Әгәр 5 литр савып та, җилен үзгәрешсез кала икән, димәк, ул шуннан артык сөт бирмәскә мөмкин. Икенчедән, гәүдәсенә карап чамаларга киңәш итәм. 550–600 кг авырлыктагы сыер бозау вакытта яхшы үскәнлеке аңлата. Өченчедән, күп сөт бирә торган сыерның аяклары нык, туры була. Аяклары көчсез сыер күп вакыт ятып тора. Ә ятып торган сыерның сөте кимрәк була. Дүртенчедән, күкрәк читлегенә игътибар итү кирәк. Ул зур, кабырга аралары киң булырга тиеш. Сөтле токымнарның башлары кечкенә, койрыклары озын була. Койрык озынлыгы сыерның сәламәт, бозау вакыттан ук нык, көчле булуын күрсәтә. Җиленгә килә торган сөт тамырлары шулай ук калын булырга тиеш.

Таналарны сайлау катлаулырак. Әниләренә карап чамалап булса да, токымнар кушылырга мөмкин. Шуңа күрә хуҗалыклардан белешергә, сорашырга киңәш итәм.

Без борынгы Кремльнең бер бизәге – зәңгәр гөмбәзле мәчетне рухи яңарыш, үткәнебез белән киләчәкне тоташтыру символы итеп кабул итәбез. Исеме дә әйтергә уңайлы, яңгырашлы. Әмма яшерен-батырын түгел, иман йортына исеме кушылган Кол Шәриф турында күбебез белеп бетерми. Бу гаҗәп тә түгел кебек, чөнки галимнәр әйтүенчә, Кол Шәриф хакында мәгълүматлар бик аз.

КОЛ ШӘРИФ

Хәтта бу бөек затның кайда һәм кайчан туганлыгы да билгеле түгел. Әдәбият галимнәре аның чын исеме Мөхәммәд Шәриф булырга тиеш дигән фикердә. «Кол» атамасы «Аллаһ колы» мәгънәсендә кушылган. Кырымда яки Хаҗитарханда (Әстерханда) туган булырга тиеш дип фаразлана, чөнки аның тәхәллүсе дә – Хаҗитархани. Кол Шәриф – талантлы шагыйрьләрнең берсе, Казан ханлыгының баш имамы, күренекле дин галиме һәм илче-дипломат, үзенең бөтен гомерен, талантын, иҗатын халык бәхете өчен фида кылган шәхес. Кол Шәриф хакындагы мәгълүматларны укучыларыбызга галимнәребезнең эзләнүләренә таянып җиткерәбез.

Сәет

Шагыйрьнең әтисе Мансур исемле булган, сәетләр нәселеннән. Ул вакытларда нәсел җепләре Мөхәммәд пәйгамбәргә барып тоташкан дин әһелләрен сәет дип атаганнар. Алар дәүләт идарәсендә зур урын биләп торганнар. Кол Шәриф үзе дә Казан ханлыгы чорына караган документларда, 1546 елдан башлап, сәет дип язылган. Әтисе үлгәннән соң аны Казан ханлыгы руханиларының башлыгы, ягъни баш имам итеп билгелиләр. Шәриф Казан ханлыгы халкы өчен әдәп-әхлак үрнәге булып санала. Аны үзе яшәгән патшалыкта гына түгел, чит мәмләкәтләрдә дә ихтирам итәләр. 1551 елның октябреннән башлап, рәсми рәвештә олуг сәет вазыйфасын башкарган. Бу – дәрәҗәсе ягыннан ханнан кала икенче урында торучы дәүләт эшлеклесе дигән сүз.

Кол Шәрифнең дәүләт эшлеклесе буларак кылган гамәлләре турында аз билгеле. Шунысы гына төгәл мәгълүм: аңа татар дәүләтенең, Казанның язмышы кыл өстендә торган иң авыр һәм катлаулы заманда эш итәргә туры килә.

Илче

Рус гаскәрләре Казанга кадәр килеп җитә. Зөя тамагында бер ай эчендә хәрби ныгытма калкып чыга. Тау ягы халкы Явыз Иванга буйсындырыла, җирләре Казаннан тартып алына. Шундый шартларда 1551 елның июнендә хөкүмәт чарасызлыктан руслар белән сөйләшүләр алып бара башлый. Илчелекнең җитәкчеләре итеп Кол Шәриф һәм кенәз Бибарс Растов билгеләнә. Ике арада шартнамә төзелә. Аның нигезендә Казан хөкүмәте тәхеткә Шаһгалине утыртырга, Сөембикә белән аның улын Мәскәүгә озатырга, Казандагы рус әсирләрен азат итәргә тиеш була. Тарихчыларның кайберләре мондый гамәлләр канкоеш булмасын өчен һәм мөстәкыйльлекне саклап калырга мөмкин булмасмы дигән өмет белән шулай эшләнә дигән фикердә. Барып чыкмый. Ахыр чиктә Явыз Иван 1552 елның 9 мартында тантаналы төстә Казанга килеп керергә тиеш була. Әмма аңа шәһәр капкасын ачучы булмый.

Казанлылар хөкүмәт башына Чапкын Отучевны утыртып куялар. Хөкүмәт составына Кол Шәрифне дә кертәләр. Отучевның төп максаты Казан ханлыгының мөстәкыйльлеген саклап калу була. Казанны алу өчен Мәскәүдән яхшы коралланган 150 мең кешелек гаскәр юлга чыга. Август аенда алар Зөя каласына килеп җитәләр. Иван патша үзе Кол Шәрифкә хат белән мөрәҗәгать итә. Казанны сугышмыйча гына бирергә дигән таләп куя. Бу таләп бертавыштан кире кагыла.

Каһарман

Август ахырларында руслар Казанны бар яктан да камап алалар. Аталык һәм Тәмән капкалары арасына, җирне казып, дары тутырылган мичкәләр куялар. Беренче шартлау 4 сентябрьдә яңгырый. Күп кеше һәлак була, әмма шәһәр халкы бирелми. Ай буена диярлек өзлексез сугышлар бара. Кол Шәриф Казан халкы өстенә килгән афәтнең коточкыч булуын сизә. Әмма аны, нишләргә, дигән сорау борчымый. Әлбәттә, халкы белән бергә булырга, ватандашларын изге сугышка рухландырырга! Кирәк икән, үзе дә соңгы сулышына кадәр көрәшәчәк, әмма кол булмаячак!

1 октябрьдә рус гаскәрләренә соңгы штурмга әзерләнергә әмер килә. 2 октябрьдә Аталык капкасы янында көчле шартлау ныгытмаларның бер өлешен юкка чыгара. Ташлар, кешеләр, бүрәнәләр, җир кантарлары – барысы да күккә оча. Шәһәрне саклаучылар аңга килергә өлгергәнче, икенче шартлау яңгырый. Рус гаскәрләре Кремльгә ябырыла. Казанлылар нык торалар, әмма көчләр тигез булмый.

Соңгы бәрелеш ныгытманың үзәгендә, Кол Шәриф мәчете янында бара. Кулларына ни туры килсә, шуның белән коралланган бер төркем мәдрәсә шәкертләре, муллалар һөҗүмгә күтәрелә. Сугыш мәйданына кулына кылыч һәм калкан тоткан Кол Шәриф үзе чыга. Моны күреп, шәкертләре тагын да кыюланып китәләр, бар көчләрен җыеп, дошман өстенә ыргылалар. Күпләре һәлак була. Исән калганнары, Кол Шәриф сәеткә ияреп, сугыша-сугыша, мәчет ягына чигенәләр. Халык арасында сакланып калган риваятьләрдә әйтелгәнчә, көрәшнең соңгы минутлары мәчет-мәдрәсә түбәсендә бара. Бу күренешне Шиһабетдин Мәрҗани менә ничек тасвирлый: «...россиялеләр Казанга һөҗүм иткәндә ул үзенең иярченнәрен җыеп, мәдрәсәгә керә һәм, мәдрәсә түбәсенә чыгып, россиялеләр белән бик каты сугыша. Руслар аны мәдрәсә (бу мәчет-мәдрәсәне шул чорда ук Кол Шәриф исеме белән йөртәләр) түбәсеннән чәнчеп төшерәләр һәм ул шулай итеп шәһит була...» Шулай итеп, 1552 елның 2 октябрендә, ил белән бергә, аның

> *«Галимнәрдән, хөрмәткә лаек габбасилардан һәм бөек сәедләрдән күпмедер шәхесләр булып, аларның башында нәкыйбел-әшраф дип танылган мелла Шәрифкол исемле бер зат тора. Ул ислам ханнары һәм шәһәр халкы алдында ихтирамга һәм зур хөрмәткә лаек була».*
>
> **Шиһабетдин Мәрҗани**

рухи остазы Кол Шәрифнең дә гомере киселә.

Шагыйрь

Кол Шәриф татар халкы күңелендә үзенең шигърияте, әсәрләре белән дә зур урын алган. Тик аның бүгенгә кадәр сакланып калган әсәрләре бик аз. Алар арасында дүрт-биш шигырь, шул исәптән «Кыйссаи Хөбби Хуҗа» исемле зур күләмле поэмасы һәм «Зафәрнамәи вилаяти Казан» («Казан иленең җиңүе») дигән чәчмә әсәре. Шигырьләрендә Кол Шәриф Аллаһы Тәгаләгә дан җырлый. Аны олыларга, һәрчак күңелдә тотарга өнди. Фани дөньяда намус белән, нәфескә бирелмичә яшәп, Алла каршына гөнаһсыз барырга чакыра. Кол Шәрифнең иҗаты, әлбәттә, болар белән генә чикләнми. Галимнәр, аларны барларга, өйрәнергә кирәк, дигән фикердә. Борынгы әсәрләрнең язмышы кульязма китапларның янгын, су басу һәм башка шундый бәла-казаларга очрамыйча сакланып килүенә бәйле була. XX гасыр башларына килеп җиткән байтак кына гарәп алфавитындагы кульязмаларыбызның 1920–1930 нчы еллардагы «ислам диненә каршы көрәш» шаукымына эләгеп юкка чыгарылуын искә төшерсәк, нинди җинаять эшләнгәнен аңлау кыен булмас. Ярый әле мондый байлыкның кадерен белүче кешеләр дә булган. «Кыйссаи Хөбби Хуҗа» әсәре 1899 елда Казан университеты нәшриятында басылып чыккан. Аны Казан өязе Курса авылының укымышлы кешесе хаҗи Шәмсетдин бине Хөсәен варислары үз акчаларына бастырып таратканнар. Кол Шәриф шигырьләренең кайберләре Төркиядә саклана торган кульязма җыентыкларда да булуы мәгълүм.

Мәчет

Татарстанның визит карточкасы, дөньядагы иң матур 10 мәчет исемлегенә кергән Кол Шәриф мәчетенең яңа тарихы 1995 елдан исәпләнә, чөнки шул елны Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев мәчет торгызу турындагы указга кул куя. Иман йорты архитекторлар Искәндәр Сәйфуллин һәм Айвар Саттаров проектлары нигезендә 2005 елда төзелеп бетә. 24 июнь көнне тантаналы төстә ишекләрен ача.

Тарихи яктан карасак, Казан Кремлендәге иң зур җәмигъ мәчет, әйткәнебезчә, ханлык чорында ук Кол Шәриф мәчете дип йөртелә. Аның даны еракларга тарала, XVI гасырда Урта Иделдә ул фәнни һәм дини үзәк була.

Мәчетнең архитектурасы күбрәк төрек һәм һинд гыйбадәтханәләрен хәтерләтә. Аның 8 манарасы бар. Гөмбәз «Казан бүреге» декоратив элементлары, лалә чәчәге (Идел буе Болгары үндырыш символы) белән бизәлгән. Мәчеттә бик еш экскурсияләр үткәрелә. Шул максаттан чыгып, архитекторлар ике балкон төзетүне күздә тотканнар. Ул биш катлы, бер мең ярым кешене сыйдыра. Ә бина каршындагы мәйданда ун меңгә якын кеше җыела ала. Чагыштыру өчен: борынгы Кол Шәриф мәчетендә дүрт йөз кеше намаз укый алган.

> *Гаҗәеп бер җәй-рәхәттер җиһанда бу Казан шәһәре!*
> *Галәмдә юктыр бу тикле туганлык вә иминлек шәһәре.*
> *Казандай төзек шәһри булмас дөньяда һичвакыт,*
> *Казаннан көч алалардыр ничаклы бу җиһан шәһәре.*
>
> **Кол Шәриф**

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ИКЕСЕНӘ БЕР ЯЗМЫШ

Авыру бала. Бу сүз бар дөньяның астын өскә китерергә сәләтле. Беребез дә бала авырганын теләми. Тик язмышлардан узып буламы соң? Алабугада яшәүче Потаниннар гаиләсендә тәрбияләнүче игезәк кызларның икесенең дә күзләре күрми.

Әмма алар бер дә моңаеп утырмый. Җырлыйлар да, төрле бәйгеләрдә дә катнашалар. Кызлар үзләренең бер дә кимсенмичә яшәүләре өчен әти-әниләренә рәхмәтле. Ярату, җылы караш аркасында без бәхетле, ди алар.

– Ирем белән гаилә коргач, бик тә сабый сөясебез килде. Ходай безгә берне түгел, ике бала бирде. Карынымда ике кызым ятканны белү минем өчен бик зур сөенеч иде, – дип сөйли әниләре Оксана. – Авырлы чакта авырмадым да, кызларны җиңел күтәрдем. УЗИ да аларның саусәламәт икәнен күрсәтте. Тапкач та, кызлар саусәламәт, диделәр. Тик соңрак без аларның күзләре күрмәгәнне чамалап алдык. Икесенә бер үк авыру иде.

Оксана бу хакта ишеткәч, ниләр кичергәнен искә төшерергә тырышмый. Үткәннәр белән яшәп булмый, ди ул.

– Күзләре күрмәсә дә, мин балаларымның башка сәләтләрен сизеп алдым. Алар бик матур итеп җырлый башлады. Биш яшь тулганда зур сәхнәләрдә чыгыш ясыйлар иде инде. Кызларым кимсенмәсен өчен бер генә бәйгене дә калдырмадык. Барган җиребездә үзләренә яңа дуслар табып кайталар. Россия эстрадасының танылган җырчысы Диана Гурцкая белән таныш алар, – ди әниләре. – Надежда белән Дарья – бер-берсенә иптәш, дус. Аларның күзләре күрмәсә дә, күңелләре бик сизгер. Гел «бишле»гә генә укыйлар.

Быел кызларым 11 нче сыйныфны тәмамлый. Җырлап кына калмыйлар, китап укырга, йөзәргә, велосипедта йөрергә яраталар.

Кызлар Алабугада яшәсә дә, көн саен 40 чакрым узып, Чаллыга барып, физик мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен махсус мәктәптә белем алалар. Әнә шулай ике шәһәр арасында йөреп, 11 ел узып киткән.

Җырларга яратсалар да, киләчәктә Надя табиб-остеопат булырга хыяллана. Үзе шигырьләр язып, шуны җырга әйләндермәкче була. Әле тагын бер хыялы бар: аңа күрмәүчеләрне йөртә торган эт кирәк. Даша исә юрист булырга тели. Аның чит илләргә барасы килә.

– Кызларымның һәр хыялын чынга ашырып яшәргә тырышабыз. Уйлап карасаң, берәүнең дә капчыгы буш түгел. Һәркемнең үз борчу-мәшәкате бар. Тормыш авырлыкларсыз гына бармый. Шуңа зарланырга яратмыйбыз. Балаларыбызны бары тик ярату аша бәхетле итәргә телибез, – ди Оксана. – Балалары авыру булган әниләргә киңәшем шул: аларны ничек бар, шулай кабул итегез. Бары тик әти-әнинең хисләре, ярдәме, яныәш булуы гына аларга яшәргә көч бирә. Инде буй җиткәч, хәзер аларның үзләреннән көч алабыз кебек. Күрмәү аларның рухларын ныгытты. Ә бу – ярату нәтиҗәсе.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

СОРОКИНА ВАЛЕНТИНА ВАСИЛЬЕВНА

(27.02.1936 – 11.01.2022)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды.

Социалистик Хезмәт Герое Сорокина Валентина Васильевнаның 11 гыйнвар көнне йөрәге тибүдән туктады.

Валентина Сорокина 1936 елның 27 февралендә ТАССР Аксубай районы Михайловка авылында дөньяга килә.

Сугыштан соңгы чорда Аксубай районының «Большевик» һәм «Восход» совхозларында дуңгыз караучы булып эшли. Үтә катлаулы эш шартлары, авыр кул хезмәте аның холкын корычтай чыныктыра. Ул бөтен тырышлыгын, осталыгын хезмәткә багышлый. Терлекләрне ашату, үрчетү, симертү буенча осталыгын камилләштерү өчен даими өйрәнә һәм алдынгы ысуллар куллана.

Валентина Васильевна терлекчелектә продукт бирүчәнлекне арттыруда югары нәтиҗәләргә ирешә. Сигезенче бишьеллыкның бурычын 3,5 ел эчендә үтәде, тугызынчы һәм унынчы бишьеллыкларда алдынгы хезмәткәр булды. Аксубай дуңгызчылык комплексын төзегәннән соң симертү цехында 1991 елга кадәр хезмәт куйды.

Ул иҗтимагый эшчәнлек белән актив төстә шөгыльләнде, 1971–1975 елларда РСФСР Югары Советы депутаты, КПССның район комитеты, партия өлкә комитеты әгъзасы итеп сайланды.

Бөтенсоюз социалистик ярышындагы казанышлары, социалистик план һәм йөкләмәләрне үтәүдәге фидакарьлеге өчен 1976 елда Валентина Сорокинага СССР Югары Советы Президиумы Указы нигезендә Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелде.

Валентина Васильевнаның күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм казанышлары шулай ук Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, Ленин ордены, «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» һәм «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы оештырылуга 100 ел» медальләре белән билгеләнде.

Ул һәрвакыт югары дәрәҗәдә хезмәт сөючәнлеге, намуслылыгы, иҗтимагый бурычка тугрылыгы белән аерылып торды. Аның тормышы – эшкә тугрылык һәм ныклык үрнәге.

Валентина Васильевна Сорокинаның якты истәлеге күңелләребездә озак сакланыр.

Р.Н. МИҢНЕХАНОВ, М.Ш. ШӘЙМИЕВ, Ф.Х. МӨХӘММӘТШИН, А.В. ПЕСОШИН, Ә.Ә. СӘФӘРОВ, М.А. ҖӘББАРОВ, Э.Ә. ЗАРИПОВА, К.К. ГЫЙЛЬМАНОВ

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе, халык депутатларының Түбән Кама шәһәр советы башкарма комитеты рәисе (1979–1985 елларда), КПССның Менделеевск район комитеты беренче секретаре (1985–1990 елларда), Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары (1992–1994 елларда) **ХАСНУЛЛИН Мансур Мингали улы**ның кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

ХАСНУЛЛИН МАНСУР МИНГАЛИ УЛЫ

(22.03.1942 – 11.01.2022)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды.

Дәүләт эшлеклесе, элекке Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Хаснуллин Мансур Мингали улы 11 гыйнвар көнне 80 нче яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Мансур Хаснуллин 1942 елның 22 мартында Свердловск өлкәсе Кировоград шәһәрендә дөньяга килә. Хезмәт эшчәнлеген 1960 елда Башкортстан АССРның Салават химия комбинатында токарь буларак башлап җибәрә. 1966 елда, Казан химия-технология институтын тәмамлаганнан соң, Түбән Кама шәһәрендә төзелеп килүче нефть химиясе комбинатына (Түбән Кама «Нефтехим») эшкә җибәрелә. 1971 елдан комбинатның профсоюз комитетында эшли. 1979 елда Түбән Кама шәһәр советы башкарма комитеты рәисе итеп билгеләнә.

Мансур Мингали улы 1985 елда Менделеевск районын оештыруда актив катнашты. 1990 елга кадәр КПССның Менделеевск район комитеты беренче секретаре вазыйфасында хезмәт куйды. Аның җитәкчелегендә районда җирле хакимият органнары булдырылды, юл төзелеше үстерелде, яңа сәнәгать һәм социаль объектлар калкып чыкты.

Ул 1990 елда ТАССР Министрлар Советының транспорт, элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлегенә җитәкче итеп куелды. 1992 ел азагында Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары вазыйфасына билгеләнде. Бу чорда аның катнашында Татарстан сәнәгать предприятиеләренең мөлкәтен һәм кадрларын саклап калу, газлаштыру, төзелеш темпларын арттыру буенча катлаулы бурычлар хәл ителде.

1994 елдан 2000 елга кадәр С.М. Киров исемендәге Казан синтетик каучук заводына җитәкчелек итте.

Мансур Хаснуллин XI чакырылыш ТАССР Югары Советы депутаты һәм II чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты итеп сайланды, Икътисади үсеш һәм реформалар мәсьәләләре буенча даими комиссия рәисе булды.

Аның күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм республиканың социаль-икътисади үсешенә зур өлеш кертүе югары дәрәҗәдәге бүләкләр белән билгеләнде. Алар арасында – Почет ордены, «Хезмәттәге фидакарьлек өчен», «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» һәм «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы оештырылуга 100 ел» медальләре, «Татарстан Республикасының атказанган химигы» мактаулы исеме, Татарстан Республикасы Мактау грамотасы.

Мансур Хаснуллин кайда гына эшләмәсен, үзен бик оста һәм гадел җитәкче, көчле һәм талантлы оештыручы итеп күрсәтте. Ташып торган көчэнергиясе, куелган максатка ирешүдәге ныклыгы аңа коллегалары һәм дуслары арасында зур абруй-хөрмәт китерде.

Хаснуллин Мансур Мингали улының якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Р.Н. МИҢНЕХАНОВ, М.Ш. ШӘЙМИЕВ, Ф.Х. МӨХӘММӘТШИН, А.В. ПЕСОШИН, Ә.Ә. СӘФӘРОВ, А.Ә. КӘРИМОВ, Ә.С. ГОБӘЙДУЛЛИН, И.Р. МЕТШИН, Р.Х. МУЛЛИН, Р.И. БЕЛЯЕВ, А.П. ЛАВРЕНТЬЕВ

РӘФИНӘ ГАНИУЛЛИНА:

«БЕЗ, БИШ БАЛА, БЕР ЙОДРЫК ИДЕК»

Татар эстрадасында халык мәхәббәтен яулаган, әмма атказанмаган моңлы җырчы Рәфинә ГАНИУЛЛИНА да бар. Халык көйләрен башкарса – моңы, заманча җырга алынса, креативлыгы белән аерылып тора ул. Хәер, гаиләләре белән дә үзенчәлекле алар. Бер ана үстергән биш кызның олысы, иң көчлеседер, командиры да улдыр, мөгаен. Аның белән татар эстрадасы хәлләре, җырга хокук, тәрбия мәсьәләләре хакында сөйләштек.

Рәфинә Ганиуллинаның шәхси архивыннан

:: Рәфинә, эстрадада гаилә белән эшләүчеләр булса да, алай ук күп түгел. Андый гаиләләрне тамашачы үзенә өлге, үрнәк итеп кабул итә. Үзегездә шундый җаваплылык тоясызмы?

– Соңгы елларда татар эстрадасында гаилә дуэтлары күбәйде. Без дә шулар исәбенә керәбез. Гәрчә мин моңа кайчандыр каршы да төшкән идем. Ул чакта миңа ир белән хатынның парлап җырлавы бик баналь тоелган иде. Тора-бара фикерем үзгәрде, чөнки чыгышларыбызга тамашачыдан аеруча бер җылылык тойдык. Шуңа күрә бүген без дуэт белән башкарыла торган җырларга өстенлек бирәбез. Әлбәттә, интернет заманында һәр кешенең тормышы күз уңында. Бигрәк тә сәхнә кешеләре кайда барганын, ниләр эшләгәнен, ниләр ашаганын күрсәтеп бара. Чыннан да, халыкны иҗат белән генә түгел, тормышыңның ачык булуы белән дә ымсындырып була. Менә шушындый болганчык заманда да үз-үзеңне югалтмаска, үзенчәлекле булып калырга, кабатланмаска иде. Яхшыдан гына үрнәк алырга кирәк. Миңа калса, тамашачыга бөтенләй үк яраклашырга ярамый. Ул бүген сине күтәрә, ә икенче көнне тәгәрәп төшәргә бер ялгыш адымың җитә. Тискәре мәгълүмат бик тиз «данлыклы» итә. Шуңа күрә алдыңны-артыңны карап йөрергә, чама хисен югалтмаска кирәк.

:: Татар эстрадасын заманча дип әйтеп буламы? Аның уңышы һәм уңышсызлыклары нәрсәдә?

– Татар эстрадасы һәрвакыт заманча булды. Без үскәндә дә, хәзер бигрәк тә. Җырчылар образларын җентекләп уйлый, сәхнә бизәлеше, аранжировкаларның сыйфатын кайгырта, матур җырлар туа. Һәр заманның үз җыры бар. Кемнәрдер ретро җырларны сагына, алардагы моң кабатланмас, ди. Килешәм. Ләкин хәзерге заманның үз яңгырашы, үз җыры. Без халык җырларын да онытмыйбыз, яңаларын да өйрәнәбез. Аралаштырып барганда, җыр да, тел дә онытылмас дип уйлыйм.

:: Соңгы араларда җырны сату-алу, башкару тирәсендә бәхәсләр чыгып алды. Ретро җырларны сату дөресме? Сүз уңаеннан, һәрбер җырчы бу өлкәдә үз хокукларын беләме?

– Кайчандыр бик популяр булган җырны башкарыр алдыннан аның авторларыннан, беренче башкаручысыннан рөхсәт алырга кирәк. Бәлки бу җырны сиңа бүләк итәрләр, бәлки сатып бирерләр. Анысы – җырчы һәм авторлар арасындагы эш. Үз һөнәренә җитди караган кеше хокукларын белә һәм һәр адымының хокукый якларын да уйлый. Нинди генә очракта да «мин белмәгәнмен, уйламаганмын» дигән сүзләр җаваплылыктан азат итми. Һәрбер җырың, чыгышың рәсмиләштерелергә тиеш. Шул очракта гына бәхәскә урын калмый.

:: Репертуар туплаганда нәрсәгә игътибар итәсез: музыкасынамы, эчтәлегенәме?

– Репертуарга килгәндә, эчтәлегенә дә, көенә дә игътибар итәбез, җиңелчә, биетә торган җырлар сайлаганда да, мәгънәле булсын, дибез. Аранжировкадан, җырның бирелешеннән күп нәрсә тора. Җыр башкаручының образына туры килмәсә, тамашачының күңеленә үтеп керә алмый.

:: Рәфинә, сезнең «Кызлы йорт» концерт программасы бар иде. Ул ни хәлдә? Сеңелләрегез белән җыелып, яңадан концерт куярга ниятләмисезме?

– «Кызлы йорт»ны уникаль проект дип саныйм һәм ул берничә сезон уңышлы эшли алыр иде. Биш бертуган кызның сәхнәгә чыгуы тамашачыга бик кызыклы булды. Бу биш талантлы кызны берүзе тәрбияләп үстергән Ана соклану уятты. Әниебез Зөлфия безнең сәләтебезне кечкенәдән тоемлап, аны шомартуда, үстерүдә зур көч куйды. Ул сәхнә киемнәрен дә юнәтте, аранжировкаларны да кайгыртты, фортепиано да сатып алды. Көндәлек мәшәкатьләренә безне төрле конкурсларга йөртүләр өстәлсә дә, беркайчан да зарланмады. Барыбызның да югары белемле булуын кайгыртты, безнең танылуыбызга ышанды. Кем белә, бәлки әле кабат җыелырбыз, әниебез хакына программа эшләрбез!

:: Биш туган – биш холык, сезнең арада кем «командир»?

– Безнең арабызда командир булырга омтылучы мин булганмындыр, мөгаен. Өлкән апа да бит әле мин. Яшермим, кайчандыр барысын да контрольдә тотарга тырышкан вакытлар булды, үземчә барыбызны туплап торырга тырыштым. Бер-беребездән аерыласы килмәү теләге дә көчле булгандыр. Без, биш кыз, бер йодрык булып үстек бит. Һаман да бергә булып булмаганын яши-яши генә аңлыйсың икән ул. Бу тормышта һәркемнең үз юлы.

:: «Инстаграм»дагы сәхифәгезгә, сеңелләре белән фотога төшми, дигән комментарий да язалар. Моның җитди сәбәпләре бармы?

– «Инстаграм»да кайбер сеңелләрем аккаунтларын бетерделәр, сәбәпләрен беләм, ләкин әйтәсем килми. Мин барлык сеңелләремне дә бик яратам, аларны ничек бар – шулай кабул итәм.

:: Рәфинә, әниегез Зөлфия апаны бала карагандай карыйсыз. Аның хәлләре ничек?

– Әниебез биш ел элек бик авыр инсульт кичерде. Ярты елга якын урын өстендә ятканнан соң, әкренләп аякка басты. Мондый могҗизаны беркем дә өмет итмәде, баш миенә кан савып операция ясагач, табиблар өч ай гомер юраган иде. Әни – көчле рухлы кеше, уң кулы эшләмәгәч, сул кулы белән ашарга, таякка таянып йөрергә өйрәнде. Дөрес, ачык итеп сөйләшә алмый, ләкин үзара аңлашып була. Тик ул мондый халәте белән бер дә килешә алмый, чөнки бик актив, оптимист кеше. Нишләп әниебезгә бераз гына булса да рәхәт, тыныч картлык насыйп булмады икән, дигән сорауга үзебез дә җавап эзлибез... Бик тә лаек иде бит югыйсә, инде бөтен авырлыкларны җиңеп чыккач кына...

:: Шундый мөмкинлек бирелсә, тормышыгызда нәрсәне үзгәртер идегез?

– Бер үкенеч бар, әни минем театр факультетына укырга керүемне теләгән иде. Нишләп шул вакытта аны тыңламадым икән, дим. Спектакльләр караганда, мин менә шушы образны ничегрәк уйнар идем икән, дип хыялланып бетәм.

:: Өч ир бала әнисе булу җиңел түгелдер?

– Рәзил белән балаларыбызның барлыгына сөенеп, тормышның бөтен тәмен, ямен тоеп яшибез. Бу дөньяда бар нәрсә дә чагыштырмача икәнен төгәл беләм, чынлап бәхетле булыр өчен аз да җитә, әмма аның өчен күп хезмәт куярга кирәк.

:: Рәзил нинди әти?

– Рәзил – игътибарлы, балаларны тәрбияләүдә актив катнаша торган яхшы әти. Кирәк икән, ботка да пешереп ашата, артын да юа, дәресен дә әзерләшә, каешның кайда икәнен дә күрсәтә белә. Монысы – ир-ат эше, монысы – хатын-кыз эше, дип бүлешеп тору юк бездә, бер-беребезгә һәрвакыт ярдәм итәбез.

:: Авыр чакта таянычыгыз кем?

– Авыр чакта таянычым – гаиләм. Гел шулай булсын иде.

:: «Дөнья мине үзгәртте, еламаска өйрәтте», – дигән шагыйрь. Ә сезне дөнья нәрсәгә өйрәтте?

– Дөнья мине көрәшергә өйрәтте. Миннән булмый, мин кемгә кирәк инде, дип үзеңнән шикләнергә ярамый, һәркемнең үзе теләгәнчә, бәхетле тормышта яшәргә хакы бар.

Блиц-сораштыру

– Сезне сәхнәгә алып чыккан җыр.
– «Үтте инде» җыры (Оскар Усманов көе, Венера Мәхмүтова сүзләре) дип уйлыйм.
– Эстраданы сайламаган булсагыз, нинди һөнәр кешесе булыр идегез?
– Бәлки укытучы булыр идем.
– Яраткан җырчыгыз, актерыгыз бармы?
– Яраткан актёрларым – Марк Руффало, Леонардо Ди Каприо. Җырчылардан Илһам Шакиров, Анна Нетребко, Алла Пугачеваны яратып тыңлыйм.
– Кешедә иң күркәм сыйфат нинди?
– Намуслылык.
– Иң ошамаган сыйфат?
– Икейөзлелек.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

< Ахыры. Башы узган елның 30 декабрь, быелның 5 гыйнвар саннарында

«Яшьлек юлəрлəге аркасында абзыең белән үзебез дә шундый хәлләрдә калдык. Батырханым ферма мөдире булып эшләгән чагында, бер савымчы хатын белән «шаяра» диган сүзләр җиткерделәр. Күзәтеп-фәлән дә йөрмәдем, уратып та тормыйча, турысын ярып сорадым: «Әгәр бу хәбәр дөрес булса, шушы минутта ук сайлыйсың, йә ул, йә мин!» Иремнең күзләре дүрт булды. Соңыннан белдек: безнең гаиләне бозар өчен, теге хатын үзе таратка булып чыкты бу хәбәрне. Әллә синең кебек минем йөрәгем янмаган дисеңме? Аракы белән мәсьәлә чишелми, бигрәк тә хатын-кыз өчен куркыныч. Безнең ата-бабалар: «Хәмер акылны каплар», – дияр иде. Ирең

– Хәзер нигә «Яшь наратлар»ны көйләгәнеңне аңладым инде, мине сатып алмакчы буласың, әйеме?

Уртанчы уллары Заһир хәйләкәр елмаеп куйды. «Кемгә охшап бу малай шома булган, ә? Хәер, аягын өздергәнче үзенең холкы да шулайрак иде. Дөнья үзгәртә кешене. Тазасау, акыллы булып үссеннәр улларым! Ә Сиринәне онытырга кирәк, онытырга! Үткәннәр үткәндә калсын. Бүген Сәбилә булып каршыңа чыккан икән, алданма! Ул – бары сине сайламаган үткәнең генә. Инвалид иргә беренче булып хатын-кыз назы, уларын бүләк иткән, гаилә мәшәкатьләренең яртысыннан күбесен үз өстенә алган Вәсимәнең кадерен белеп, балаларны бергә тәрбияләп яшәргә нәрсә комачаулый соң сиңа, шайтан алгыры!»

ЛЮЦИЯ ӘБЛИЕВА

(ХИКӘЯ)

«НАРАТ БАШЫННАН КОРЫЙ»

белән кара-каршы утырып сөйләшегез, аңлашыгыз. «Нарат башыннан корый, әнә шул башны сакларга кирәк. Үстереп, кеше итәсе балаларыгыз бар. Начар итеп кабул итмә, яхшылык теләвемне соңыннан аңларсың. Ни дисәң дә, син миңа чит кеше түгел, әбиең белән ахирәтләр идек, урыны оҗмахта булсын!»

***

Кинода гына бит проблемалар җиңел чишелә. Тормыш икенчерәк. Фәрихәттәй кушканны үтәп, барысы да шул минутта җайга салынса, оҗмах булыр иде ул. «Кайчан сөйләшәсең көне-төне эштәге ир белән?»

Вәсимә, ихатада сәпитен төзәтеп торган олы улына көтү каршыларга кушып, өйгә үтте. Башта кочагына ташланган кече улы: «Әни, синнән тәмсез ис килә», – дип, өстәл астында ширпы капларыннан ясалган «гараж»ына кереп качты. «Азаккы тапкыр» дип, Рәйбәләрдә ике генә рюмка эчеп чыккан Вәсимә, кечесенең сизгер борынына ачуы килеп, диванга шапылдап килеп утырды. «Эшкә чыгам, булды, җитте! Әнә Рәйбәнең ире төзелештә пешекчеләр кирәк ди, район үзәгенә йөреп эшли башлыйм». Шушы уйлар белән йоклап китеп барганда гына, Зилфәт кайтып керде.

– Нишләп ятасың, көтү кайтты ич, сыерны кем сава?

– Бигрәк коры син, хәлләрең ничек дип сорап ичмасам! Бер олы индыр бәрәңгене алу әллә җиңел дип уйлыйсыңмы?

– Хәлләрең кызганырлыкка охшап тормый әле, күңелләрең күтәренке! Малайлар ярдәм итмәдемени?

– Аларның ярдәме күпме генә инде, дәрестән кайтканнарын көтеп утырыйммыни?

Вәсимә, язылып бетмәгән аркаларын көчкә күтәреп, дәшми генә абзарга чыгып китте. Зилфәт Таһирның «гараж»ына кереп, хәлен белеп чыккач, телевизорны кабызып, «Яңалыклар» карарга утырды.

«Басылмады йөрәк ярсулары,
Басылса да юллар тузаны.
Синең җырың шунда калган кебек,
Яшь наратка карап узамын».

– Сөбханалла! Улым, кайчан өйрәндең әле бу җырны?

– Әти, мин аны туганчы ук белгәнмен кебек тоела.

Зилфәт рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

– Вәт, шәп җавап бирдең, улым! Бик булырга мөмкин! Кара син аны, «туганчы ук белгәнмен кебек тоела» дисең инде.

– Әти, математикадан синсез булмый. Тегеләй дә чишеп карадым, болай да, кыскасы, берничек тә килеп чыкмады. Әни сыер савып кергәнче карап алыйк әле!

***

– Йә инде, кәнфитләнеп утырма, эчкәнеңне беләбез.

– Әйтмә дә, бүген төшкән килен кебек көйләтеп утырган була.

– Беренче зарплатаны көн дә алмыйбыз.

– Эчмәскә сүз бирдем, кыстамагыз!

– Алла-а-а, патша кызы диярсең. Беребез дә күктән төшмәгәнбез инде, шул бер җирдән төшкәнбез.

Барысы да вагончик эчен яңгыратып көлеп җибәрделәр. Вәсимәгә бу шаяру кызык тоелмады. Ай буе иртәнге алтыда чыгып китеп, кичке җидедә кайтып керүләре арыткан иде шул. Дөрес, кеше арасында эшләп йөрү, ни дисәң дә, күңелле. Зилфәт белән аралары да яхшы якка үзгәрде кебек. Тик менә балаларын җәлли. Көне буе үзләре генә. Ире төшке аш вакытында кайтып, күз-колак булып китсә дә, әни, ни дисәң дә, әни инде. «Фу, онытып торам, акча алдым бит, кибетләргә кереп чыгыйм, күчтәнәчләр алыйм! Ашыгырга кирәк, көне көн төсле түгел – күз ачкысыз буран. Җитмәсә, аяк асты да бозлавык».

Вәсимә тулы сумкалар белән туктылышка килеп җиткәндә, халык, түгәрәк ясап, җыелып тора иде. Баганаларның сүрән лампочкаларыннан төшкән яктылык астында, юлда бөкрәеп яткан бәләкәй генә гәүдә чагылып китте. «Карчык тәки машина астына кергән икән… Шулай инде, эчү юньлегә илтми», – диештеләр шунда җыелып торганнар. Вәсимәгә юл уртасында, беркайчан да күрмәгән карчык түгел, үзе яткан кебек тоелып, тәне эссе-ле-суыклы булып китте. Куркыныч уйлардан арынырга теләп, шыңгырдап торган нараттан салынган өйләрендә көтеп утырган балаларын, ирен күз алдына китерде. Аннан туктылыштан алгарак китеп, машина көтә башлады. Ул арада җил дә бераз әкренәйгәндәй, буран басылгандай булды.

– Вәсимә!

«Колагыма ишетеләме әллә?» – дип шикләнеп, тавыш килгән якка башын борырга куркып торганда, берәү килеп, сак кына иңнәренә кагылды.

– Зилфәт?!

– Өйдә көяләнеп утырганчы, килеп алыйм дидем.

– Балалар нишли?

– Бар да тәртип, сине көтәләр.

Машина кузгалып киткәч, Зилфәт әкрен генә яраткан җырын сузды. Вәсимә аңа кушылды.

«Яшь наратлар көен җырлап киттең
Көмеш кыңгыраулы пар атта.
Озатып кайтам сине, карый-карый
Бөдрәләнеп үскән наратка».

Хезмәттәшебез, «Мәхәббәт чәе», «Җыр керсен күңелгә», «Азалия», «Карлы яңгыр», «Көнләшмә» кебек танылган җырлар авторы Нариман Камалов бу көннәрдә 80 яшен тутырды. Туктаусыз хәрәкәттә булган, иҗат дәрте ташып торган тугры дустыбызга саулык-сәламәтлек, бәрәкәтле тормыш, күтәренке рух телибез. Укучыларыбызга исә шагыйрьнең яңа гына табадан төшкән шигырьләрен тәкъдим итәбез.



Нариман КАМАЛОВ

БУ ДӨНЬЯНЫҢ МИН ПАТШАСЫ БҮГЕН!..

Глобус әйләндерәм… Күрегезче!
Минем кулда дөнья – Җир шары.
Минем кулда болытлардан төшкән
Урал тауларының ак кары.
Минем кулда – Казан, Мәскәү, Париж…
Минем кулда җиһан – бар галәм.
Бу дөньяның мин патшасы бүген –
Рәхмәт сиңа, Ходай Тәгаләм.

Мин – иминлек патшасы!
Белегез:
Чик-кирталәр алып ташлана.
Җир шарында дус-туганлык белән
Яңа эра бүген башлана.
Йә әйтегез, кемгә кирәк сугыш? –
Без бит туган бер үк анадан.
Туган җиребез дә Җир шары бит,
Алганбыз көч, куәт аңардан.
Глобус әйләндерәм… Фантазия!
Минем кулда тарих – чор ташы…
Минем кулда тормыш – җир, су, һава;
Минем кулда галәм кояшы.

КЫШ БАБАЙНЫҢ УЛЫ – БҮЛӘГЕ МИН

Кыш бабайның улы – бүләге мин
Тантаналы бәйрәм таңында.
Җир шарына илһам тавыш бирел
Курантлар суккан чагында.

Биләүдәге тәүге тавышымнан
Тетрәнгәндәй булды Җир шары.
Әй, коелды өстән, болытлардан
Яңа елның энҗе ак кары.

Ап-ак карлар, иреннәрем үбеп,
Дөнья гүзәллеген сөйләде.
Күзләремне ачып, керфекләрем
Барыр юлларыма төбәде.

Алда, күрәсеңдер, кыя-таулар,
Кабырчыклы диңгез сулары.
Миңа диеп Магелланнан калган
Салынмаган эзсез юллары.

Киләчәккә – өмет, алда – дәвам,
Алда – хыял, юлның чиксезе.
Көтә мине, төннәр йокламыйча,
Җидегән, Марс, Зөһрә йолдызы.

…Көтә мине, әллә зарыкканмы –
Бәйгеләргә сыймый тулпарым.
Тезгеннәрен өзеп, башын чөеп
Ватып чыкмак була утарын.

Көмеш тояк акбүз атым минем
Җитезлеккә җитез – ук аткан.
Вакытларны узып китәр өчен,
Яңа гасыр, миңа ач капкаң!

МИН – СИНЕҢ УЛЫҢ, МӘҢГЕЛЕК!

Рәссам-скульптор Бакый Урманчега

Тыңлап торам. Тавыш килә һаман,
Кемдер чокый – ташка уямы?
Җансыз ташка җан кертергә теләп,
Үз йөрәген берсе куямы?
Үзе җырлый «Randomly Фәхри» җырын,
Таныш җыр бу… Тукта!
Кем җырлый?
Тавышыннан ташлар уянганнар,
Таш Тукай да гүя җыр тыңлый.
Аһәң тавыш, йөрәк тулы сагыш…
Чал ташларның мизгел чыңнары –
Еллар аша дәверләрне үтеп
Ишетелә бүген чынлавы.
Тыңлап торам. Тавыш килә һаман,
Кемдер чокый – ташка уямы?
Җансыз ташка җан кертергә теләп,
Үз йөрәген берсе куямы?
Әллә аргамагы биеп тора –
Тояклары көмеш дагамы?
Әллә юлчы, төн кунарга сорап,
Чор капкасын шулай кагамы?
Дәвер түзми, чыга яланаяк.
Дәвер сорый:
– Анда кем шакый?
– Ач капкаңны, әй, Мәңгелек,
Синең улың булам, мин – Бакый!

ДӨНЬЯ ХӘРӘКӘТТӘ

Галәм – океан, йолдызлар – маяк,
Җир – зур кораб, илләр төялгән.
Ак шәлен япкан кар таулары
Җир-корабта гүя ак җилкән.

Ә без исә шушы Җир-корабта
Пассажирлар гына тик бары.
…Җиде бабам әйткән, мин дә әйтәм:
«Хәерле юл сиңа, Җир шары».

БЕР КАЙТЫРМЫН ӘЛЕ…

Капка ярыгыннан карап кала
Киленнәре, малай-шалае.
Очраганы кушаматы белән
Исәнме, ди, «Батрый» малае!

Исән-исән! Инде китеп барам…
Сау бул, дустым, диям бар(ы)сына.
Эчләренә хәтта сәлам бирәм
Өреп чыккан чакта каршыма.

Хуш, авылым! Тагын бер кайтырмын
Дәва үләннәре җыярга.
Мәтрүшкәле тәмле чәйләр эчеп
Авыл ямен, гамен тоярга.

Безнең кавем, нәсел-шәҗәрәбез
Туфрагында, туган авылым.
Сиксәндә дә бер кайтырмын әле,
Иншалла! Ходай гына бирсен саулыгым.

Авылдашлар бабам кушаматын
Онытканнар булыр шул заман.
Яңа буын үз исемем белән,
Кайткан, дияр, шагыйрь Нариман.

Язучы фикере

ӨЧЕНЧЕ ЮЛ

«Икенең берен сайла!» – диләр. Берсен сайлыйсың. Бер адым атлауга, тагын тормыш сорау куя: икенең берен сайла. Алдыңда торган шул икенең берсе дә сайларлык түгел икән, бу – тупыйкка килеп төртелү дигән сүз. Сиздермичә генә кире чиген дә тагын икенең берен сайла. Без шуңа күнеккәнбез, без шулай яшибез.

Бот буе гына чагымда дус малай янына кердем. Өйдә ялгызы гына бу. Әби-бабасы юк. Әти-әнисе эштә. Гадәти хәл инде авылда. Әле син сабыйны ялгыз калдырулары җитмәгән, өстәвенә әллә күпме эш тә кушып китәләр...

Бәләкәй кеше тик торамыни инде, пыр тузабыз, анысын-монысын актарынабыз. Бер мәлне кайдандыр наручниклар килеп чыкты. Чып-чын богау инде. Милициянеке. Мин моны алай-болай әйләндердем дә бер боҗрасын иптәш малайның беләгенә эләктердем, икенчесен – караватаягына. Чытырт итеп ябылды бу. Кызык. Икебез дә көлешәбез. Көлеп туйгач, ычкындырырга итеп карасак, ычкынмый теге. Озак кына маташа торгач, бу гамәлнең кызыгы бетте. Берәр җирдә түгелме дип ачкычын эзләргә булдык. Теге малай «шунда түгелме икән» дип әйтеп кенә тора инде, мин актарынам. Юк, табылмый. Бераздан малайның су эчәсе килә башлады. Мин чүмеч белән су алып килдем. Бераздан алма ашарга теләде, мин бакчаларына чыгып алма алып кердем. Аннан соң урамдагы су колонкасына кеше җыела башлады. Су сәгать унбердән уникегә кадәр генә була, аннан соң туктый. Өлгермәсәң – үзең гаепле. Миңа да суга чыгарга кирәк. Өлкәннәр үзләре өйдә булмаса да, эш кушып китә бит алар. Дус малай көйсезләнә: «Су ташып куярга кушканнар иде, хәзер ничек итим инде?!» – ди. Икебез өчен дә ташып куярга туры килде. Ә башкача ничек итәсең? Үзем гаепле: мин эләктердем, мин ычкындырырга тиеш. Ычкындырырлык түгел. Кисеп булмый аны, балта белән чабып булмый. Икенең бере кала – я ачкычын табасың, я су ташыйсың.

Савытларын тутырып бетерүгә, дус малайның печ итәсе килә башлады. Юынтык су сала торган чиләкләрен китереп куярга туры килде. Ул эшен бетергәч, түгеп тә кердем. Икенең бере – нишлисең. Ачкычын табалмагач, барысын да эшләргә мәҗбүрсең. Төш җитте. Чәй куеп эчерергә, йомырка пешереп ашатырга туры килде. Алар арасында ачкыч эзлим, ачкыч табылмаса, нишләргә мөмкин, дип баш ватам. Юк. Берни башка килми. Ташлап китәргә дә ярамый ич инде, үземнең дус бит.

Бәхеткә, сәгать дүртләр тула дигәндә әнисе кайтып керде. Ул бу хәлне күреп, бер-ике матур сүз генә әйтеп алды да... карават аягын күтәрде... һәм боҗраның бер ягы шуып чыкты... Моны күреп мин телсез калдым. Әллә ничә тапкыр пар чиләкләр күтәреп су ташып йөргәнче, караватның бер аягын гына күтәрергә кирәк булган лабаса! Мин икенең берен сайладым. Өченче юлны эзләргә кирәк булган...

Кеше куян куа диеп... бер танышым да үз эшен, үз бизнесын ачарга булды. Матур гына бер җирдә машиналар кую урыны булдырды бу. Шуны төзим, дип бурычка батып бетсә дә, эше һич алга китмәде. Сәбәбе дә бар иде. Шәһәрнең тыныч урыны – урлашучы юк, талаучы юк. Хәтта кичтән бикләргә онытсаң да, машинаң иртәнгә кадәр шул килеш тора. Шулай булгач, кемнең түләүле стоянкага куясы килсен инде?! Моңа хәзер ике генә юл бар: яки бу бизнестан котылырга, яки аны башка урында ачарга. Аптырап калган эшкуарга шулай киңәш итәләр белгән кешеләр, икенең берсен сайла, өметсез эш бу, диләр. Һәм эшкуар бу автостоянканы сатарга уйлый. Ләкин башкалар да сантый түгел, бер табыш китерми торган бизнесны хәтта бик арзанга да алырга теләүче юк.

Һәм эшкуар... өченче юлны сайлый. Янган өч автомобиль табып ала. Бер төнне машиналарның берсен бер ишегалдына куеп китә. Аннан соң тагын бер ишегалдына... Һәм бераздан тегенең стоянкасы эшли башлый.

Кемнең машинасын яндырганнар? Бу сорауга төгәл җавап бирә алучы юк. Ләкин бу мөһим дә түгел. Иң мөһиме – кемнеңдер машинасын яндырганнар. Өстәвенә күрше ишегалдында да бер янган машина тора. Алла сакласын!..

Әлбәттә, мондый мисалларны күпләп китерергә мөмкин булыр иде. Мин башкача санап тормыйм, теләсәгез, үз тормышыгыздан үзегез мисаллар табыгыз. Мисаллар күп, ә хакыйкать берәү генә: икенең берсен сайларга тиеш булган котылгысыз хәлләрдә һәрвакыт өченче юлны сайларга кирәк.

Марат КӘБИРОВ

КОТЛЫЙБЫЗ!

Гыйнвар аенда кадерле кешеләребез – Алексеевск районы Зур Тигәнәле авылында яшәүче әтиебез, дәү әтиебез **Нәсыйхов Равил Мөбарәкҗан улы** һәм Казан егете – улыбыз **Әскәр**нең туган көннәре. Гомер бәйрәмнәре белән котлап, саулык-сәламәтлек, бәрәкәтле имин тормыш, иман ныклыгы, туганнар-якыннар җылысы телибез.

Әти! Ата-ана һәм туган кадерен белергә өйрәткәнең, туган нигезгә кайтканда кочак җәеп каршы алуың өчен бик зур рәхмәт сиңа. Өебез һәрвакыт ямьле, ризыклы булсын, балаларыгызның, оныкларыгызның игелеген күреп, әниебез Фәния белән бер-берегезгә куаныч, терәк, ышаныч булып, озак гомер итегез. Алдагы көннәреңдә дә сау-сәламәт булып, безнең шатлыкларга сөенеп яшәргә язсын иде. Улыбызның бәхетле, тәүфыйклы, мәрхәмәтле булып, тормышта үз юлын табуын телибез.

Иң изге теләкләр белән, әниебез Фәния, Фәнил, Ландыш – Эльдар, Диләрә.



Рәис Габдулла

5 гыйнвар санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: хөр, рокфор, малахит, Спас, Хәят, Арес, лаз, Әнәс, алабай, нар, Лев, хром, Егор, Ван, Ансат, инану, Лира, статика, Оса. **Вертикаль буенча:** Сулавеси, Гела, Натс, Авзалова, Брамс, НАТО, Аурис, укол, рәйхан, Ика, Ахен, сыла, Хо, Хәсәнова, өрфия, Самат, Отт.


«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА
РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 18156 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 204

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәрриренең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+